Формирование функциональной грамотности – это сложный процесс, который требует от учителя использования современных методов и приемов обучения. Применяя все эти приемы и методы на уроках, можно воспитать самостоятельную и творческую личность.

***"Учитесь так, словно вы постоянно ощущаете нехватку своих знаний, словно вы постоянно боитесь растерять свои знания"***

Конфуций

Библиографический список

1. Хасеинова В. А. О подготовке педагогов к формированию функциональной грамотности и компетентности учащихся на уроках русского языка и литературы // Открытая школа. — № 2–2014.
2. Бирибаева Н. Ж. Пути практической реализации «Национального плана на 2012–2016 годы по развитию фунгциональной грамотности школьников// Уроки русского языка и литературы в школе. – № 6–2013.
3. Колесникова, И. П. Формирование функциональной грамотности на уроках русского языка и литературы / И. П. Колесникова. — Текст : непосредственный // Молодой ученый. — 2016. — № 7.3 (111.3). — С. 15-17.

**Петухова Н.П., учитель русского языка и литературы**
**высшей квалификационной категории**
**МБОУ «Тетюшская средняя общеобразовательная школа №2»**

## ТЕКСТ КАК ОДНА ИЗ ФОРМ ФОРМИРОВАНИЯ ФУНКЦИОНАЛЬНОЙ ГРАМОТНОСТИ

Аннотация

Данная статья показывает, что текст создаёт оптимальные условия для работы по формированию функциональной грамотности обучающихся в эпоху развития информационных технологий. В ней продемонстрированы разные формы работы с текстом, развивающие предметные, коммуникативные и универсальные компетенции, приведены примеры из опыта работы по рассматриваемым позициям. Предложенные приёмы работы с текстом обеспечивают эффективное обучение в рамках реализации ФГОС и позволяют учитывать способности и возможности каждого.

Ключевые слова: функциональная грамотность, виды текстов, продуктивное чтение, многообразие видов грамматического разбора, коммуникативные и предметные компетенции.

Современная жизнь предъявляет сегодня человеку жёсткие требования – это высокое качество образования, коммуникабельность, целеустремлённость, креативность, а самое главное – умение ориентироваться в большом потоке информации и адаптироваться в любом обществе. Поэтому школа должна не только формировать предметные знания и умения, но и развивать у обучающихся умение использовать свои знания в решении различных жизненных проблем. Это формирует функциональную грамотность – тот уровень грамотности, который позволяет человеку жить полноценной жизнью в обществе.

Самой сложной, но самой важной составляющей функциональной грамотности является языковая грамотность.

Работа с текстом на уроках русского языка - средство повышения функциональной грамотности школьников. Современный этап развития методики обучения языку

характеризуется тенденцией слияния языка и речи в единое целое. Материалом для такого комплексного обучения на моих уроках служит текст. Художественный текст - яркий образец выразительной и красивой речи; публицистический, научный, официально-деловой тексты - источники информации. Например, при изучении односоставных определенно-личных предложений обращаюсь к лирике А.С. Пушкина; при изучении сложных предложений с разными видами связи использую отрывки из произведений Л.Н. Толстого, И.А. Бунина и др. Практикую использование текстов разных авторов на определенную тему или же применяю отрывки только одного автора. Вариантов работы с текстами художественных произведений очень много. На их основе работаю со школьниками разной обучаемости.

Также использую тексты из газет с примерами из реальной жизни, статьи, содержание которых связаны с повседневной жизнью ученика и помогают решать ему жизненно важные проблемы. Например, такие: «Внимание вирус!», «Осторожно гололёд!», «Соблюдайте правила пожарной безопасности!» и другие. В качестве материалов для учебных заданий использую объявления, рекламу, инструкции, меню, входные билеты и т.д., связанные с поиском, пониманием, преобразованием и использованием этой информации в разных жизненных ситуациях.

Что мне даёт работа с текстом?

Во-первых, в век массовой увлечённости компьютером текст на уроке - образец литературного языка, правильного, выразительного, в котором слово выступает во всём своём богатстве и красоте. Во-вторых, положительные эмоции, вызванные интересным содержанием текста, влияют на эффективность работы учеников. В-третьих, текст содержит большой воспитательный потенциал, жизненный материал. В-четвёртых, он позволяет охватить огромный программный материал. В-пятых, текст даёт возможность дифференцированно подбирать материал, формы работы, учитывая индивидуальные способности каждого. В-шестых, работа с текстом - средство развития коммуникативной компетенции.

На уроках обобщения и закрепления работаю с концентрированными текстами. К их подбору и адаптации привлекаю творческую группу учеников. Приведу пример такого текста, который использовала на обобщающем уроке по теме: «Вводные слова и обращения. Междометия».

Два друга.

(1)Вчера Вовку и Лёшку, ко всеобщему удивлению, не могли разбудить. Принимали самые жестокие меры. Во-первых, их поднимали, но они опять падали на кровать, во-вторых, их щекотали, так как, по словам мамы, они боятся щекотки, в-третьих, на них даже поливали из чайника. Но всё было бесполезно. Вовка болтал ногами и кричал: «Ой-ой, помогите, люди добрые!» А Лёшка почему-то махал руками и вопил: «Ура!» По совету дедушки, их оставили в покое. Мама, правда, подходила к ним и говорила: «Мальчики, хотите мороженое?» (2)Но братья (а они очень любили мороженое) не поддавались на провокацию. (3)Проспали они, по нашим подсчётам, сорок девять часов. Кажется, они всё-таки добьются своего и попадут в Книгу рекордов Гиннесса.

Работая над данным текстом, использую приёмы продуктивного чтения, который состоит из 3-х этапов.

На этапе предтекстовой деятельности использую приём «говорящий заголовок»: предлагаю составить рассказ, ориентируясь на заглавие.

На этапе текстовой деятельности предлагаю «двойной дневник»: записать в 1-ую колонку – что понравилось, во 2-ую – почему.

На третьем, послетекстовом этапе, задаём «тонкие и толстые вопросы». Понравились ли вам мальчики? Как автор относится к мальчикам? Прочитайте текст без вводных слов, обращений, междометий. Что изменилось в тексте? А также составляем шпаргалки по вводным словам, объявляю «конкурс шпаргалок».

Эти приёмы помогают ученикам глубже осмысливать текст и изучаемую тему, повышают речевую культуру, а значит - развивают функциональную грамотность. При работе с текстами других типов и стилей эффективны другие приёмы репродуктивного чтения: на первом этапе - «образ текста», «верные и неверные утверждения»; на втором этапе - «читаем парой», «чтение по кругу», на третьем этапе - «кубик Блума», «дырявое письмо» и т.д.

Далее проводим работу по формированию у обучающихся предметных умений и навыков, выполняя орфографические и пунктуационные задания по группам:

1 - в тексте расставить все пропущенные знаки препинания, произвести синтаксический разбор 1-го предложения.

2 - выписать из текста вводные слова и словосочетания, определить их значения, произвести синтаксический разбор 2-го предложения.

3 - выписать из текста с расставленными знаками препинания вводные слова и словосочетания, произвести синтаксический разбор 3-го предложения.

Также проводится коллективная работа по правописанию трудных слов, выявлению самостоятельных и служебных частей речи, повторению знаков препинания при прямой речи со всеми группами, после чего 2-ая и 3-я группы объясняют правописание безударных гласных в корнях глаголов, правописание приставок, сильная группа делает сообщение о Книге рекордов Гиннесса.

Текст предоставляет большие возможности для работы с разными видами грамматических разборов. Грамматический разбор - традиционная и эффективная форма учебной деятельности - позволяет использовать задания разной сложности и формирует в основном предметные компетенции. В зависимости от темы урока, от его задач в центре внимания может быть какой-либо один вид разбора, который отрабатывается в максимальной полноте, или же производим сразу несколько видов разбора, менее полных, но многосторонне характеризующих то или иное языковое явление. Разнообразие видов грамматического разбора дает широкие возможности для работы с учениками, но требует упорядочения, умения вовремя переключаться с одного вида работы на другой. Виды разборов очень тесно связаны между собой, и эти связи между разными разделами языка учащиеся обнаруживают при работе с текстом, выполняя самые различные виды анализов.

Умение работать с текстом как основным источником информации способствует развитию коммуникативных способностей и умений обучающихся, совершенствует правописную грамотность и является одним из действенных средств, способных вызвать интерес к уроку и развивать функциональную грамотность.

***Список использованной литературы:***

1. Н. Н. Абдуллина. Развитие функциональной грамотности на уроках русского языка.
2. Т.И. Акатова. Языковая функциональная грамотность и языковая культура. — Психолого-педагогический аспект: Монография. - М., 2006г. с. 237
3. С. Курганов. «Ребенок и взрослый в учебном диалоге» - М., 2005, с.91
4. Е. В. Рой. Формирование функциональной грамотности у обучающихся.
5. Селевко, Г.К. Современные образовательные технологии: учеб. пособие / Г.К. Селевко. – М., 1998.
6. Халперн, Д. Психология критического мышления / Д. Халперн. – СПб., 2000. – (Сер. «Мастера психологии»).
7. Якиманская И.С. Разработка технологий личностно ориентированного обучения// Вопросы психологии. – 1995. - №2. – С. 24-25

**Плечева Т.В.,учитель русского языка и литературы**
**высшей квалификационной категории**
**МБОУ ООШ №8 г.Бугульма РТ**

## ПРОЕКТНЫЕ ТЕХНОЛОГИИ НА УРОКАХ РУССКОГО ЯЗЫКА И ЛИТЕРАТУРЫ

Сейчас существует наибольшая потребность в людях, не только имеющих достаточный запас профессиональных знаний и умений, но и способных самостоятельно выстраивать стратегию собственной жизни, умеющих «создавать» самих себя. Обществу необходим человек, обладающий высоким уровнем видения себя настоящего и себя же в будущем, человек с творческой активностью, ответственностью, решительностью, способностью и желанием учиться , человек , умеющий анализировать информацию, прогнозировать результат, проектировать свою деятельность, выбирать необходимое. Все это предъявляет новые требования к качеству образования на всех уровнях, что закреплено в новом Федеральном государственном образовательном стандарте.

Современное образования определяет одной из основных задач раскрытие потенциала всех участников образовательного процесса через предоставление им возможностей проявления своих творческих способностей. Решение данных задач возможно только путем вариативности образовательных процессов. В связи с этим появляются различные инновационные педагогические технологии, которые способствуют повышению эффективности обучения. Поиск решений, которые, оптимизировав учебный процесс, помогут сформировать положительную мотивацию обучающихся к изучению учебного материала и создадут условия полного раскрытия

их креативного и интеллектуального потенциала, разовьют их познавательные интересы, приводит к инновационному образованию, позволяющему сделать учебную деятельность максимально эффективной.

«Инновационное образование в современных российских условиях реализуется через инновационную деятельность, результаты которой должны выражаться в следующем. Обучащиеся могут:

1. Свободно обращаться с различными типами источников информации (учебники, словари, электронные, аудио- и видеоносители, интернет- ресурсы).
2. Быстро находить и правильно использовать информацию необходимую для выполнения профессиональных (или других) задач.
3. Самообучаться.
4. Самостоятельно принимать решения.
5. Быстро адаптироваться в новом коллективе;
6. Обладать хорошими коммуникационными навыками и навыками социального взаимодействия;
7. Быть социально-ответственными; в своих поступках и действиях опираться на общечеловеческие морально-этические принципы» (В.С. Сизов ИННОВАЦИИ В ОБРАЗОВАНИИ Экономика образования ♦ №2, 2013 с/54-64)

Одной из наиболее часто используемых инновационных форм является проектная технология.

Метод проектов- одна из личностно-ориентированных технологий, сочетающая в себе проблемный подход, исследовательские и поисковые методы обучения. Внедряя данный метод в повседневную педагогическую деятельность, каждый из нас задавал себе ряд вопросов:

- ✓ Что такое учебный проект?
- ✓ Как выбрать тему проекта?
- ✓ Каковы этапы проектной деятельности?
- ✓ Как организовать работу над проектами при изучении русского языка и литературы?
- ✓ Как правильно оформить презентацию проекта?

Разобраться со всем этим мне помогло написанное А.Г.Нарушевичем пособие «Русский язык. Проекты? Проекты.. Проекты!» («Легион», Ростов-на Дону,2013). Изучив его, я предложила попробовать создать проект ученицам 7 класса. Вместе с ними определили темы творческих проектов «Портрет одного слова» : «Слово «царь» в сказках А.С.Пушкина.» и «Слово «Балда » в «Сказке о попе и работнике его Балде» А.С.Пушкина.» Такие темы были взяты неслучайно, а с прицелом участвовать впоследствии в Открытом Республиканском творческом конкурсе «Пушкинские чтения». Определившись с темой, составили план предстоящей работы, обозначили круг вопросов, которые должны найти отражение в проекте, определили словари и интернет-ресурсы, которые можно использовать при подготовке проекта, наметили сроки реализации проекта. Через определенное время собранный материал отсортировали, выбрали наиболее интересные факты и составили модель представления проекта, с обязательным указанием целей и задач, которые были решены в процессе работы. Создание проекта «Портрет одного слова» позволило развивать навыки <u>индивидуальной</u> работы по плану, предложенному учителем: этимология слова, его значение в

различных словарях, словообразовательное гнездо, частотность употребления слова в определенном тексте и т.п. Работая с различными источниками, девочки учились выбирать самое важное из огромного объема информации, приобретая навык анализа , столь нужный в современном мире.

В результате получили проект «Портрет одного слова», который включает в себя разнообразную информацию об этимологии слов «царь» и «балда», их значении и употреблении в малых формах русского фольклора. Используя различные толковые словари , ученицы провели сравнение дефиниций(толкований) данных слов, которые в них даны. Составили словообразовательное гнездо. В «Энциклопедии литературных героев» В.В.Макарова узнали, почему именно имя Балда было выбрано А.С.Пушкиным для своего героя. Также было проанализировано использование слов «царь» и «балда» в современном языке. В итоге получились работы, позволяющие «увидеть» слово с разных сторон. Эти проекты позволили сформировать первичные навыки исследовательской деятельности учениц и реализовать их творческие способности.

Проектная деятельность предполагает индивидуальные, парные и групповые формы работы , формирует личностные, познавательные, регулятивные и коммуникационные УУД, развитие которых обязательно по новым Федеральным государственным образовательным стандартам.

Проектная деятельность возможна не только при подготовке к участию в различных конкурсах и конференциях, она важна и на обычных уроках.

Так,при изучении темы «Фразеологизмы» я предлагала реализовать групповой проект о фразеологизмах определенной тематики: «Обозначение мыслительной деятельности»(зарубить на носу, иметь в виду, выбросить из головы и др.), «Эмоционально-физическое состояние»(болеть душой, висеть на волоске, ни жив ни мертв, на седьмом небе и др.), «Характеристика человека»(тише воды ниже травы, не лезет за словом в карман, ни рыба ни мясо и др.). Здесь учащиеся рассказывали о толковании данного фразеологизма, об истории его появления, о сфере употребления и особенностях написания. Таким образом, они учились работать с различными источниками информации, развивали коммуникативные навыки работы в группе, совершенствовали умения публичного выступления- представления своего проекта. Также в процессе работы некоторые ребята пробовали создавать презентации своего проекта; не всегда удачно, но без проб и ошибок опыта не приобрести.

Это проект вызывает интерес со стороны учащихся, так как при его подготовке дети учатся работать в группе, выполнять задания по определенному направлению темы и координировать свои результаты, создавая групповой продукт. А это одно из тех умений, которое востребовано в современном обществе. Подобные проекты повышают уровень сформированности коммуникативных и познавательных УУД.

Парную форму работы над проектом можно использовать на уроке русского языка ,например, при изучении темы «Заимствованные слова» . При создании проекта по определенным группам иноязычных слов, класс делиться на пары, которые получают задание рассказать о заимствованных словах, пришедших из конкретного языка: греческого, немецкого, английского, французского и т.д. Эта работа, как правило, рассчитана на взаимодействие соседей по парте.

На уроках литературы проектная технология была применена на уроке в 9классе при изучении темы «Романтизм». Я предложила классу разделиться на группы и

рассказать о романтизме не только как о литературном направлении, но и направлении в искусстве Х!Х века в целом. Учащиеся подготовили презентации и рассказали о романтизме в музыке, живописи и литературе. Этот урок позволил проявиться различным талантам учащихся: они играли на музыкальных инструментах Алябьева , слушали Чайковского, декламировали стихи Байрона и Баратынского, рассказывали о художниках Франсиско Гойя и Карле Брюллове. В итоге проекты, приготовленные учащимися , позволили им расширить свои знания в общекультурном плане, показать свои коммуникативные навыки, креативные способности и умение работать в группе.

Проектные технологии – одно из направлений работы учителя, предусмотренной Федеральным государственным образовательным стандартом. Применение их в моей практике показало эффективность такой работы и дало результат успеха моим учащимся. Так, например, учащиеся разных лет Абдрахманова Л. , Хасанова А, Шульман Р., готовившие проект «Портрет одного слова» , участвовали в творческом конкурсе «Пушкинские чтения» и заняли там третье место. А работа Абдрахмановой Л. была напечатана в сборнике материалов межрегиональной конференции «Развитие и сохранение национальных языков в поликультурном пространстве»(2016). Навыки проектной деятельности пригодились и в исследовательской работе. Так, ученик 8 класса Газизов И., готовя проект к юбилею Победы «Их именами названы улицы», заинтересовался вопросом годонимов района школы, и из его проекта выросла исследовательская работа «Бугульминские годонимы: к вопросу о наименовании улиц района «Подстанция» , которую он представлял на Республиканской научно-исследовательской конференции «Молодежь в научном поиске» и занял 1 место. Эта работа была отмечена и дипломом 3 степени Всероссийского конкурса научно-исследовательских и творческих работ, проведенного Российской академией естествознания.

В заключение хочется сказать, что проектная технология развивает познавательные интересы обучающихся, способствует повышению их личной уверенности, развивает “командный дух”, коммуникабельность и умение сотрудничать. При создании проекта ведущая роль в деятельности отводится самим ученикам, а учитель становится консультантом и координатором, направляет работу в нужное русло. Хочется отметить, что все ребята, участвующие в проектах, очень гордятся своей работой, проявляют активность и самостоятельность в поиске и обработке информации. Проектная технология на уроках русского языка и литературы позволяет сформировать у учащихся лингвистическую, речевую и социокультурную компетенцию. Такая деятельность способствует развитию творческих способностей и логического мышления, учит самостоятельно добывать знания из различных источников и эффективно их применять в процессе учебы, причем не только на уроках русского языка и литературы. Таким образом, в результате проектной деятельности формируются универсальные учебные действия, что отвечает требованиям нового Федерального государственного образовательного стандарта.

**Сөнгатуллина Г.Г., татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

**Муниципаль бюджет гомумбелем учреждениесе**

**Теләче муниципаль районы Теләче урта гомуми белем бирү мәктәбе**

**ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ФУНКЦИОНАЛЬ ГРАМОТАЛЫЛЫК ФОРМАЛАШТЫРУ**

Аннотация: Хәзерге мәктәпнең төп бурычларыннан берсе булып функциональ яктан белемле кешеләр формалаштыру. Хәзерге мәктәпнең төп бурычларыннан берсе булып функциональ яктан белемле кешеләр формалаштыру. Татар теле дәресләрендә функциональ грамоталылыкка төрле чаралар ярдәмендә ирешергә мөмкин. Укытучы теге яки бу күнегүнең нинди максат белән кулланылганын ачык күз алдына китерергә тиеш, укучы татар телендә сөйләшсен, иркен аралашсын өчен мөмкин булган барлык метод һәм алымнарны күзалларга тиеш.

Хәзерге мәктәпнең төп бурычларыннан берсе булып функциональ яктан белемле кешеләр формалаштыру. Нәрсә соң ул функциональ грамоталалык? Функциональ грамоталалык – кешенең тышкы тирәлек белән бәйләнешкә керә алуы һәм анда тиз арада яраклашуы.

Дәрестә функциональ грамоталылык формалаштыру – ул балаларга җәмгыятьтә үз урынын таба алырлык итеп белем, тәрбия һәм күнекмәләр бирү дигән сүз.

Татар теле дәресләрендә функциональ грамоталылыкка төрле чаралар ярдәмендә ирешергә мөмкин. Укытучы теге яки бу күнегүнең нинди максат белән кулланылганын ачык күз алдына китерергә тиеш, укучы татар телендә сөйләшсен, иркен аралашсын өчен мөмкин булган барлык метод һәм алымнарны күзалларга тиеш. Моның өчен укытучыга шәхескә юнәлдерелгән коммуникатив методларны файдалану кирәк.

5-6 сыйныфларда терәк схемалар, рольле уеннар, лексик таблицалар актив кулланам. Уңай нәтиҗә булып укучыларның өйрәнгән лексиканы куллана белүләре, сөйләмнәрен синонимнар белән баетулары тора.

Уен технологиясе башлангыч һәм урта сыйныфларда һәрбер дәрестә диярлек бар. Бу уеннар реаль тормышка: балаларга, аларның мөмкинлекләренә, конкрет дәрескә бик якын торалар. Рольле уеннар коммуникатив технологияләр формалаштыруга ярдәм итәләр.

Телнең лексик запасын арттыру өчен, сөйләмне баету өчен дәресләрдә мәкаль-әйтемнәр, фразеологизмнар, хәрәкәтле физминуткалар үткәрергә тырышам.

Коммуникатив грамоталылык формалаштыру группада, командада эшләүне, башка кешеләрне үзеңә тартуны, төрле яңа шартларга һәм тәртипләргә яраклашуны, группада эшне оештыру, татар телендә аралашу һәм диалог төзү кебек күнекмәләрне үз эченә ала.

Уку-укытуда диалогик сөйләмне куллану укучыларның интеллектуаль үсешенә уңай тәэсир ясый.

Дәресләрдә ИКТ технологияләр кулллану да функциональ грамоталылык формалаштыруда әһәмиятле роль уйный. Төрле темага караган видеофильмнар, мультфильмнар, видеороликлар өйрәнелә торган темаларны киңрәк үзләштерергә ярдәм итә.

Укучылар татар теле дәресләрендә тәнкыйди фикерләүне үстерүгә корылган биремнәрне дә үтиләр.

Мәсәлән, “кластерлар” алымын еш кулланам.

Кластер дәрес материалын график калыпка салуны күздә тота. Төп мәгънәне белдергән сүз уртага языла, аңардан төрле якка киткән уклар бу сүзне ачыклаучы башка

сүз, сүзтезмәләр белән бәйли. Шулай итеп, бер сүзне, төшенчәне ачыклаучы бик күп мәгълүмат җыела, яңа сүзләр үзләштерелә. Синквейн - рефлексия этабы өчен иң уңайлы алым.

Рус балаларына татар теле укытканда укучыларның текст белән эшләвен еш кулланам. Бу текстны уку, яки тәрҗемә итү генә түгел, функциональ грамоталылык күнекмәләре булдыруга караган биремнәр үтәү мөһим. Мондый хаталы текстларны кабатлау өчен материал буларак та, төрле конкурс һәм олимпиадаларга, йомгаклау аттестацияләренә әзерләнгәндә дә кулланырга мөмкин.

1. Яңа теманы өйрәнгәндә: төшеп калган сүзләрне, сүзтезмәләрне, тотрыклы сүзтезмәләрне өстәп язарга, дөрес эзлеклелектә язарга, хаталарны табарга һәм башкалар.
2. Үтелгән материалны кабатлаганда.
3. Үтелгән материалны ныгытканда.
4. Белемнәрне тикшергәндә.
5. Укчыларның иҗади эшен оештырганда.

Эш методлары бу очракта төрле булырга мөмкин: белемнәрне мөстәкыйль үзләштерү чарасы буларак мөстәкыйль эш ( парларда һәм төркемнәрдә эш), укытучы җитәкчелегендә коллектив эш.

Функциональ грамоталылык күнекмәләре формалашкан укучы күпкырлы уку төрләрен куллана белә. Мин үз укучыларымны текстлар, сүзлекләр, кулланмаларны белеп файдаланырга өйрәтергә тырышам.

Тема буенча иҗади эшләрнең ахыргы этабында мин проект методын кулланам. Бу укучыларның шәхси мөмкинлекләрен ачарга ярдәм итә.төрле темага кагылышлы проектларны яклаганда татар телендә сөйләшү киңәя.

Киләчәктә ниндидер нәтиҗә булсын өчен, кайсы юнәлештә эш алып бару кирәклеген ачыклау өчен кире элемтә дә мөһим. Шуңа күрә мин татар теле дәресләрендә рефлексияне кулланам. Шуны истә тотарга кирәк: укыту барышында белем алу гына түгел, укучының дәрестән нинди хис-кичерешләр белән китүен дә исәпкә алу кирәк.

Югарыда санап үтелгән биремнәр балаларга үз фикерләрен ачык, төгәлитеп формалаштырырга, өйрәнелгәнне яхшырак истә калдырырга ярдәм итә. Дәрес барышында һәр баланың эшен, җавабын тыңлап, бәя бирәм.

Укытучының төп максаты – ныклы белем бирү, укучыларны тормыштагы проблемалы ситуацияләрне чишү өчен төрле чараларны кулланырга өйрәтү.

Файдаланылган әдәбият исемлеге:

1. Ермоленко В. А., Перченок Р. Л., Черноглазкин С. Ю. Дидактические основы функциональной грамотности в современных условиях. Рос. акад. образования. Ин-т теории образования и педагогики. – М., 1999 г.

**Садриева Г.Г.,**
**учитель татарского языка и литературы первой квалификационной категории**
**МБОУ «Тетюшская СОШ №1 имени Ханжина П.С» г. Тетюши**

# ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ПРОЕКТ ЭШЧӘНЛЕГЕ

Бүгенге көндә проект сүзе бик популяр. Телеведение, интернет челтәрләрендә, газета-журналларда да проект сүзен еш ишетәбез. Нинди генә проектлар юк? “Телевизион проект”, “Җыр проекты”, “Бию проектлары”, “Ана теле проекты”, “Интернет-проектлар”.һ.б. Проект сүзе нәрсәне аңлата соң?

Проект– ул әле булмаган нәрсәне (мисал өчен, яңа бинаны, программаны) барлыкка китерүгә юнәлтелгән һәм аның тормышка ашу процессын күзаллаган бер идея, уй-теләк. Шуның өчен дә проект алдына куелган максат төзү, барлыкка китерү, булдыру, иҗат итү, ирешү һ.б. кебек фигыльләр ярдәмендә формалаштырыла. Шулай итеп, проект – ул:

1) нинди дә булса механизмның яки корылманың планы;

2) нинди дә булса документның алдан әзерләнгән тексты;

3) теләгеңне тормышка ашыру планы.

«Проект» - фарсы теленнән алга атлаучы, алдан баручы дигәнне аңлата. Проект методын куллану – ул алган белем һәм күнекмәләрне системалаштыру, «белү һәм белмәү» зонасында мөстәкыйль эшчәнлек кору, фәннәр арасында бәйләнеш табу, дулкынлардырган проблеманы билгеләү, чишү юлларын табу, эш нәтиҗәсен тәкъдим итә алу.

Проект методының асылы: укучылар укытучы җитәкчелегендә эзлекле рәвештә проектлар эшлиләр, проект өстендә эшләгәндә өстәмә информация туплыйлар һәм һәр этапка рефлекция ясыйлар.

Укучы өчен проект нәрсә соң ул?

иҗади мөмкинлекләрен ачу;

төркемдә эшләү күнекмәләре булдыру;

үзе сайлаган кызыклы проблеманы (теманы)ачу өстендә эшләү ;

үзенең эшен (хезмәтен) презентацияләү.

Проект төрләре

Урта сыйныф укучылары арасында кызыксынуларына нигезләнеп, төрле типтагы проектлар эшләнергә мөмкин:

Тикшеренү.

Иҗади.

Уен.

Мәгълүмати.

Социаль.

Һәр типтагы проектта аерым тукталып үтәм.

Тикшеренү проекты:

- хәзерге заманда актуаль булган тема алына;
- проблемасы күрсәтелә;
- тикшерү объекты билгеләнә;
- тикшеренү ысуллары күрсәтелә;
- нәтиҗә чыгарыла.

1. Тикшеренү проекты белән эзләнү-тикшеренү эшенең аермасы:

Проектның асылы – белем алу шартларында туган проблеманы чишү ысулларын ачык.

Эзләнүнең асылы – алган белемгә таянып билгеле бер объектка юнәлтелгән теория һәм практиканы гомумиләштереп фараз (гипотеза) яклау

Үзенчәлеге

- Проект эшчәнлегендә нәтиҗәдә һәрвакыт продукт була
- Проект кыска вакытлы булырга мөмкин
- Проект
- Проблема
- Гамәлгә ашыру нияте
- Реализация
- Рефлексия
- Презентация

Продукт: реферат, спектакль,доклад,газета, фильм,ярдәмлекләр,альбомнар

Эзләнү эшчәнлегенең төп продукты – ул яңа белемнәр

- Ешрак эзләнү озак вакыттны таләп итә
- Эзләнү
- Кызыксындырган сорау
- Гипотеза чыгару
- Чыганаклардан эзләнү
- Теоретик белемнәрне гомумиләштереп
- Тупланган һәм эшкәртелгән мәгълүматларга таянган чыгыш ясау

2. Иҗади проектлар. Бу типтагы проектларның төгәл структурасы юк. Эшнең төренә билгеләнгән таләпләр буенча эшләнә. Моңа газета, буклетлар чыгару, презентацияләр сценарияләр язу керә.

3. Уен проектлары. Уен проекты дәрескә, махсус конкурска әзерләнергә һәм тулысынча тиешле тематикага туры килергә тиеш. Мондый проектларда структурага әз генә төгәллек кертелә, ләкин ул ахырга кадәр ачык кала. Катнашучылар проектның эчтәлеге таләп иткән билгеле бер характердагы рольләрне алалар. Болар әдәби персонажлар яки уйлар чыгарылган мифик геройлар булырга мөмкин. Бу эшчәнлектә көтелгән нәтиҗә бары тик азакта гына була.

4. Мәгълүмати проектлар. Нинди дә булса объект турында мәгълүмат җыю, анализлау. Мәсәлән, шәһәребез музее, җәмигъ мәчете турындагы проект эшләре.

. Проектларны фән юнәлеше белән бәйле рәвештә өч төргә бүләргә мөмкин:

1. Монопроект. Программаның укучылар өчен катлаулырак өлешен алып, бер фән кысаларында гына эшләнә. Дәрес вакытында үткәрелә.

2. Фәнара проекты. Ике яки күбрәк фәнне үз эченә алып, дәрестән тыш вакытта үткәрелә

3. Төп уку фәннәреннән тыш булган проект. Бу төре мәктәптә фән буларак укытылмый торган юнәлешне үз эченә ала. Дәрестән тыш вакытта үткәрелә

Үткәрү масштабына бәйле рәвештә дүрт төргә бүленә:

1. Сыйныф проекты. Бер генә сыйныфта үткәрелә.
2. Мәктәп проекты. Мәктәп эчендә, бер фәннән дәрес вакытында үткәрелә.

3. Региональ проект. Берничә мәктәп арасында оештырыла, ләкин бер регион яки бер ил эчендә үткәрелә.

4. Халыкара проект. Ике ил арасында үткәрелә.

Катнашучылар санына карап өч төргә бүленә:

1. Шәхси. Бер кеше тарафыннан эшләнә.
2. Парлы. Проект өстендә ике кеше эшли.
3. Төркемдә. Бер проект өстендә бөтен төркем укучылары эшли.

Дәвамлылыгына карап:

1. Кыска вакытлы проект (бер дәрес, ике күбе алты дәрес).
2. Уртача вакытлы (бер яки ике ай).
3. Озак вакытлы (бер елга кадәр).

Проект — бу «биш П»:

Проблема – Планлаштыру – Информация эзләү (Поиск информации) – Продукт – Презентация

Проект эшләүнең түбәндәге этапларын билгеләп үтәргә мөмкин.

1. Беренче “П” . Әзерлек этабы, аны “кереш өлеш” яки “проектка кереп китү” дип тә атарга мөмкин:

-проектның темасын, максатын һәм проблемасын билгеләү;

-проблеманың әһәмиятен нигезләү;

-проект башкару өчен укучыларның шәхси теләкләрен искә алып, төркемнәргә бүлү.

Укытучы бу этапта укучыларга проект өчен төрле темалар тәкъдим итә. Укучылар үзләре тәкъдим иткән темалар карала. Бу этап проектның иң демократик өлеше булып тора.Теге яки башка теманы сайлату өчен укучыга басым ясау, укучы башкарырга теләгән проектны кире кагу рөхсәт ителми.Укытучы ярдәме белән, укучылар үзләре кабул иткән проектның проблемасын, сюжетын, максат һәм бурычларын билгелиләр, куелган максатны тормышка ашыру юлларын эзлиләр.

Проект һәр укучы тарафыннан аерым яки иҗади төркемнәрдә эшләнергә мөмкин.

2. Икенче “П”. Эшчәнлекне планлаштыру һәм проблемаларны чишү этабы яки “эшчәнлекне оештыру” дип тә атасак була --проблемалы ситуацияләрдән чыгу юлларын эзләү;

3. Өченче “П” . Информация эзләү .

-киләчәк нәтиҗәне презентацияләү формасын һәм алымын сайлау.Укучылар бу этапта мәгълүмат эзлиләр, җыялар, тәртипкә китереп анализлыйлар, эшне планлаштыралар; укытучы белән киңәшләшеп, киләчәк нәтиҗәне презентацияләү формасын һәм алымын сайлыйлар; әзерлек һәм планлаштыру эшенә үзбәя бирәләр.

4. Дүртенче “П” . Проектны тормышка ашыру (продукт дисәк була):

-анализ юлы белән табылган мәгълүматларны бер бөтенгә берләштерү, нәтиҗәне дәлилле аңлату.Укучылар үзләре башкарган эшкә анализ ясыйлар, уңышларын һәм кимчелекле якларын ачыклыйлар, нәтиҗә чыгаралар.

5. Бишенче “П”. Проектны яклау, проект эшчәнлегенең нәтиҗәләрен бәяләү этабы.

Укучылар проектны презентациялиләр, башкаларны эш нәтиҗәләре белән таныштыралар, сорауларга җавап бирәләр, эшчәнлекләренә үзбәя бирәләр.Бу этап

бигрәк тә әһәмиятле булып тора.Һәрбер проект уңышлы тәмамланырга тиеш. Бала эшләгән эшеннән канәгатьләнү хисләре кичереп калсын.Эш тәмамланганда төрле күргәзмәләр үткәрсәң, балаларга грамоталар,сертификатлар, медальләр бирсәң отышлы була. Төрле формадагы презентацияләрне кулланырга була:спектакль, күргәзмә, викторина, гомуми темага мини-проектлар, викторина һ.б.

Укытучы проект белән җитәкчелек итү барышында төрле рольләргә керергә тиеш була:

-эшне оештыручы консультант-киңәшче;

-вакытны дөрес бүлергә өйрәтүче җитәкче;

-хаталарын һәм җитешсезлекләрне күрсәтүче, сораулар бирүче;

-төркемнәрнең координаторы;

-башкарылган эшне анализлаучы эксперт- тикшерүче.

Проект эшенә ата-аналарны да җәлеп итү бик отышлы, ата-ана бала тормышында актив катнаша башлый.

Укучыларга проект эшчәнлегенә йомгак ясаганда:

1.Проект эшендә нәрсә кызыклы булды?

2.Аеруча нәрсә ошады?

3.Нинди яңалыклар белдең?

4.Бу теманы өйрәнүне дәвам итәр идеңме?

5.Киләчәктә нинди проект эшен дәвам итәр идең? -кебек сораулар бирергә була.

Проект эше үрнәкләре

Минем гаиләм ( стенд)

Авазлар һәм хәрефләр (рәсемле таблица)

Шәһәрләр (карта)

Килеш кушымчалары ( ярдәмлек)

Татар костюмы (презентация

Татар һәм рус бәйрәмнәре ( таблица, мәкалә)

Истәлекле урыннар ( доклад)

Безнең шәһәр ( презентация)

Татар теле үзенчәлекләре ( чагыштырма схемалар)

Синоним сүзләр (сүзлекчә)

Сүз төркемнәре (буклет)

9 – 11 нче сыйныф:

Якташ язучылар ( доклад –презентация)

Татарлар чыгышы ( альбом, мәкалә)

Бәйлек сүзләр ( таблица)

Сүзләр тарихы ( сүзлек)

Кушма җөмлә ( ярдәмлек)

Татарларның язу тарихы (күрсәтмә-доклад)

Алынма сүзләр ( доклад –презентация )

Укучылар белән ел саен Камай укуларында, фәнни- гамәли конференцияләрдә катнашам. Чермянина Анна, Горланова Арина, Каляканов Евгений белән катнашып төрле дәрәҗәдәге дипломнар белән бүләкләндек Бу конференцияләргә әзерләнгәндә укучылар үзләредә кызыклы мәгълүматларны төрле чыганаклардан эзлиләр. Ни кызганыч, татар телендә иркен аралашучы укучыларыбыз елдан ел кими бара, шуңа күрә

башка миллэт балаларында проект эшчәнлегенә җәлеп итергә тырышам. Быел 9 сыйныф укучысы Марцева Надя белән “Мое имя в мире имен” исемле проект эше якларга әзерләнәбез. Эш бик кызыклы һәм нәтиҗәле булыр дип өмет итәм..

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә проектлар методын куллану – укучыларның иҗади сәләтен үстерүгә этәргеч булып тора. Укучыларда яңа проектлар эшләү теләге туа һәм фәнгә карата кызыксыну уяна. Иҗади эшчәнлек тәҗрибәсенә ия булган саен укучыларның белем сыйфаты да үсә.

Кулланылган әдәбият:


1 Белобородов Н.В. Социальные творческие проекты в школе. М.: Аркти, 2006

2 Бычков А.В. Метод проектов в современной школе. – М., 2000

3 Землянская Е.Н. Учебные проекты младших школьников. // Нач.школа. – 2005 -

4 Лакоценина Т.П. Современный урок. – Ростов на Дону: Учитель, 2007

5 Пахомова Н.Ю. Метод учебного проекта в образовательном учреждении. – М.,

6 Пахомова Н.Ю. Учебный проект: его возможности. //Учитель. – 2000.,№4.



**Сафина З.С., Нурлат шәһәре 2 нче урта гомуми белем мәктәбенең туган тел һәм әдәбияты укытучысы**


# ПРОЕКТНАЯ ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ В ОБРАЗОВАТЕЛЬНОМ ПРОСТРАНСТВЕ КАК ЭФФЕКТИВНОЕ СРЕДСТВО ДОСТИЖЕНИЯ НОВОГО КАЧЕСТВА ОБРАЗОВАНИЯ


Аннотация

Бу мәкаләдә проектлау методы бары тик укытучы һәм укучы эшчәнлеген тиешле бәйләнештә алып барганда гына югары нәтиҗәләр бирүе турында сүз бара.


«Проект» - фарсы теленнән алга атлаучы, алдан баручы дигәнне аңлата. Проект методын куллану -ул алган белем һәм күнекмәләрне системалаштыру, «белү һәм белмәү» зонасында мөстәкыйль эшчәнлек кору, фәннәр арасында бәйләнеш табу, проблеманы билгеләү, чишү юлларын табу, эш нәтиҗәсен тәкъдим итә алу. Проект-ул конкрет проблеманы хәл итүгә, алдан планлаштырылган нәтиҗәгә оптималь ысул белән ирешүгә юнәлдерелгән эш. Проектлар методы педагогикада берничә елдан артык кулланыла. Әлеге метод шәхеснең иҗади мөмкинлекләрен активлаштыруга, уку эшчәнлегенең яңа формаларын ачыклауга ориентлаша.

Проектлау методын кулланганда укытучы һәм укучыларның аралашуы, хезмәттәшлек итүе үзенчәлекле төс ала: укытучы укучыларның эшчәнлеге белән генә түгел, аларның бергәләп эшләве, фикер алышуы, карар кабул итүе белән дә идарә итәргә тиеш. Бу укытучыдан балаларның аралашу культурасына аеруча игътибар итүне таләп итә. Проектлау методы бары тик укытучы һәм укучы эшчәнлеген тиешле бәйләнештә алып барганда гына югары нәтиҗәләр бирә.

Шулай итеп, проект – ул:

1) нинди дә булса механизмның яки корылманың планы;

2) нинди дә булса документның алдан әзерләнгән тексты;

3) теләгеңне тормышка ашыру планы.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә проект эшчәнлегенең берничә төре: мәгълүмати, рольле, практик юнәлешле, иҗади һәм тикшеренү проектларын аерып алырга мөмкин.

Мәгълүмати проект нинди дә булса объект турында мәгълүмат җыюга, аны анализлау, гомумиләштерү һәм киң аудитория өчен тәкъдим итүгә юнәлдерелгән. Мәсәлән, теге яки бу язучының яки шагыйрьнең биографик мәгълүматлары буенча китап булдыру.

Рольле проектта укучылар уйлап чыгарылган геройларның әдәби яки тарихи персонажлары ролен үз өстенә ала. Мәсәлән, теләсә кайсы әсәрнең эпизодын, әкиятләр инсценировкасы күрсәтү.

Татар теле һәм әдәбияты буенча гамәли юнәлешле проект, проектта катнашучыларның социаль мәнфәгатьләренә юнәлдерелгән. Мәсәлән, татар теле буенча кагыйдәләр ни өчен өйрәнелә,хәзерге тормышта кагыйдәләрне белү кирәк булырмы?

Иҗади проект максималь ирекле һәм традицион булмаган нәтиҗәләрне рәсмиләштерүгә якын килүне күздә тота. Татар теле һәм әдәбияты буенча проектларның озынлыгы төрлечә..
Мини-проектларны бер дәрес эчендә эшләргә мөмкин. Мәсәлән,” язучылар турында сүз” яки“ минем яраткан язучыларым”.

Татар теле һәм әдәбияты буенча кыска вакытлы проектлар ике-дүрт дәрес алып тора. Атналык проектлар төркемнәрдә башкарыла. Эш укытучы җитәкчелегендә бара.

Татар теле һәм әдәбияты буенча еллык проектлар төркемнәрдә дә, индивидуаль рәвештә дә башкарылырга мөмкин. Ел саен үткәрелә торган проект – проблемаларны һәм теманы билгеләүдән алып презентациягә кадәр-дәрестән тыш вакытта башкарыла. Бу җитди тикшеренү, аны яклау мәктәп һәм муниципаль фәнни-гамәли конференцияләрдә ешрак үткәрелә.

Проектларның күптөрлелеге укытучыга яшүсмерләрне укыту һәм тәрбияләүнең төрле мәсьәләләрен алар өчен кызыклы формада хәл итәргә мөмкинлек бирә. Бу укучыларга белем һәм күнекмәләрне актив кулланырга, үз уку арсеналын киңәйтергә, ә аннары алган тәҗрибәне башка уку-укыту һәм укудан тыш эш төрләренә күчерергә мөмкинлек бирә. [2, 188].

Проектлар методы фәнне өйрәнү өчен бирелә торган барлык уку вакыты дәвамында, мөстәкыйль танып-белү, гамәли һәм сәнгать-иҗади эш алымнарының һәм формаларының күптөрлелеген кулланып, чын-чынлап тикшеренү иҗади мөстәкыйль эшчәнлекне оештырырга мөмкинлек бирә. Проект методикалары бүген заманча мәгариф системасының компонентларының берсе булып тора. Аның асылын чагылдыручы проектлар методының мөһим билгесе булып укучыларның мөстәкыйль эшчәнлеге тора. Алар уку процессының актив катнашучылары булып торалар. [4;17]

Заманча мәктәптә проект эшчәнлеге методын куллануның түбәндәге актуаль өстенлекләрен билгеләп үтәргә мөмкин:

1. Укучыларның мөстәкыйльлеген арттыру.
2. 1 Яңа материалны үзләштерү. Дәреслек, сүзлек белән эш итә белү.
3. Укучыларның укуда мотивациясен арттыру.
4. Укучыларның танып-белү мәнфәгатьләрен активлаштыру.

5. Проект эшләрен башкару белән шөгыльләнүче укучыларның үз-үзләренә бәя бирергә өйрәтү.

6. Укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү.

7. Барлык укучыларны да коллектив фикерләү эшчәнлегенә җәлеп итү.

8. Коллективта эшли белү, аралашу күнекмәләрен үстерү.

9. Үз-үзеңне һәм үз эшеңне тәкъдим итү күнекмәләрен төрле формаларда: телдән, язма рәвештә, өр-яңа технологик чаралар куллана белү.

10. Күпчелек проектларның практик әһәмияте яшүсмерләрне социумда тормышка әзерләргә мөмкинлек бирә.

Шулай итеп, проект эшчәнлеге хәзерге заман мәгарифендә социализация процессында оператив белемнәр белән тәэмин итү буенча иң перспективалы юнәлешләрнең берсе булып тора. [3;4]

Нәтиҗә буларак, кешене иҗат итәргә мәҗбүр итү мөмкин түгел. Фантаст А.Азимов үзенең "Һөнәр" дигән искиткеч хикәясендә язганча, кеше үз теләге белән эшкә килергә, сынап карарга һәм ялгышырга тиеш. Иҗат итү хокукын якларга әзер булган кеше генә чын иҗатка сәләтле, ә татар теле һәм әдәбияты укытучыларының бурычы- укучыларны бу иҗатка мотивлаштыру, аларга үзләренең кечкенә һәм зур ачышларын ясарга ярдәм итү. Яшь буын зиһенле, фикер йөртә белүче, җәмгыятькә файдалы шәхес булырга тиеш. Чөнки балалар – безнең киләчәгебез. Ә киләчәк тормышны кору өчен сәламәт, зиһенле кешеләр кирәк.

Файдаланылган әдәбият:

1., – Проектная деятельность школьников в разновозрастных группах. – М.: Просвещение, 2013.
2. Дубровская деятельность на уроках литературы в рамках реализации ФГОС [Электронный ресурс] , Режим доступа //http://www. anedu. ru/uo/docs/documents/nortativ_pravov/uo/31-4.pdf
3. Литература. 5-11 классы: проектная деятельность учащихся / сост. . – Волгоград: Учитель, 2012. – 283 с.
4.Пахомова учебного проекта в образовательном учреждении. – М.: АРКТИ, 2008.

**Сафина Р.И.,**
**Нурлат шәһәре 8 нче урта гомумбелем бирү**
**мәктәбенең югары категорияле туган тел**
**һәм әдәбияты укытучысы**

Аннотация

Бу проект эше укучыларда мөстәкыйль эшли белү күнекмәләре булдыруга, осталыклар камилләштерүгә, укучыларның Нурлат ягыннан чыккан күренекле шәхесләрнең иҗаты буенча белемнәрен тулыландыруга юнәлдерелгән. Шулай ук укучыларда үз халкына һәм теленә милли горурлык тәрбияләү, тел аркылы халкыбызның тарихын, гореф-гадәтләрен, психологиясен өйрәнүгә дә нык игътибар бирелде.

Заман таләпләре бүгенге көндә татар телен укыту процессында зур үзгәреш

сорый. Укытучыларыбыз алдында бик тә җаваплы һәм әһәмиятле бурыч тора. Беренчедән, телебезне саклап калу бурычы булса, икенчедән, балаларда телне өйрәнүгә кызыксынуны бетермәү, киресенчә, бу кызыксынуны үстерү бурычы. Бу укытучыдан зур һөнәри осталык, түземлелек һәм заман таләп иткәнчә, югары технологияләрдән, мәгълүмати чаралардан хәбәрдар булуын таләп итә. Бүгенге көн укытучыдан иҗади эшли белүне таләп итә. Педагогик эшчәнлектә иҗадилык - бу, беренче чиратта, яңалыкка, үзгәрүчәнлеккә омтылу.

Кешенең матур истәлекләре, изге хыяллары, иң беренче шатлык – куанычлары аның балачагы яки үсмер чагы белән бәйләнгән була. Менә шушы матур истәлекләр арасында шактый урынны мәктәп, балачак дуслары, әлбәттә, укытучылар алып тора. Иң беренче мәктәп бусагасын атлап кергән көннән алып зур тормышка озатып, соңгы кыңгырау чыңлаган көнгә кадәр бала белән һәрчак янәшәдә аның укытучысы атлый. Ул аны белем дөньясына алып керә, яхшыны яманнан аерырга, хезмәт һәм иҗат шатлыгын тоярга өйрәтә, фикерләү сәләтен үстерә, дөньяга карашын формалаштыра, аңардан шәхес тәрбияләүгә бөтен көчен куя. Укыту – тәрбия эшендә иң мөһиме – баланы уйларга, эзләнергә, үз алдында торган мәсьәләләрне мөстәкыйль хәл итәргә өйрәтү. Дәрестә һәм дәрестән тыш вакытта укыту – тәрбия эшен максатчан һәм эзлекле оештыру – шәхес формалаштыруның һәм үстерүнең нәтиҗәле юлы. Без һәрвакыт укучыларның сыйныфтан тыш эшчәнлеген оештыруга зур игътибар бирәбез, чөнки фәнне тирәнтен үзләштерүдә, тел культурасын үстерүдә, мөстәкыйльлек тәрбияләүдә сыйныфтан тыш эшләрнең әһәмияте зур. Татар теленнән дәрес материалын җиңел үзләштерүче укучылар белән беррәттән авыр үзләштерүче балалар да бар. Шунлыктан укучыларны шушы фән белән кызыксындыру өчен сыйныфтан тыш чаралар үткәрүнең роле зур. Материалны авыр үзләштерүче балалар да бу чараларда бик теләп катнашалар һәм аларның уйлау, фикерләү сәләтләре үсә бара. Укучылар өчен мәҗбүри булмауга карамастан, татар теле буенча дәрестән тыш чаралар һәр укытучының ныклы игътибарын таләп итә. Дәрестән тыш чараларда укытучы укучыларының кызыксынуларын, сорауларын, мөмкинчелекләрен тулысынча канәгатьләндерә ала. Сыйныфтан тыш чаралар программа буенча каралган белем эшчәнлеген тулыландыра һәм укучыларның уку материалын тирәнтен үзләштерүләренә ярдәм итә.

Тәкъдим ителә торган “ Татар телендә төп гомуми белем бирү оешмаларының югары сыйныф укучылары өчен дәрестән тыш чаралар үткәрү үзенчәлекләре: түгәрәк эшчәнлеге” дип аталган әлеге махсус проектның эчтәлеге дә укучыларның сорауларын һәм ихтыяҗларын исәпкә алып төзелде.

Мәктәптә үткәрелә торган сыйныфтан тыш чара- түгәрәк эшчәнлеге колачын һәм эчтәлеген һәрдаим үзгәртеп торабыз. Әдәби викториналар, КВН, тел бәйгеләре, танылган язучыларының тормыш һәм иҗат юллары белән танышу кичәләре һ.б. үткәрүләр гадәткә керде. Уен рәвешендә үткәрелгән сыйныфтан тыш чаралар балалар күңелендә һәрвакыт рухи канәгатьләнү хисе калдыра. Алар укучыларның бергәләп эшләү һәм үзара аралашу, ярдәмләшү күнекмәләрен, иҗади сәләтләрен үстерергә, фәнгә булган кызыксынуларын арттыра. Базар икътисадының бүгенге таләпләре һәм мәгълүмати җәмгыятьнең тиз темплар белән формалашуы мәгариф системасы алдында яшь буынга белем бирү максатын һәм бурычларын, форма һәм эчтәлеген тамырыннан үзгәртү мәсьәләсен куйды.

Түгәрәк эшчәнлеге белем биреп кенә калмый, ә мөстәкыйль эшчәнлек

күнекмәләрен булдырырга һәм һәр баланың шәхси мөмкинлекләрен ачарга, өлкән сыйныфларда укыячак профильне сайларга ярдәм итә. Әлеге проект материаллары филология һәм журналистика факультетларына укырга

керергә теләүче укучылар һәм алар белән эшләүче укытучылар өчен дә уңышлы ярдәмлек булыр.

Туган як. Туган туфрак.Туган төбәк. Бу сүзләр өлкән яшьтәге кешеләр өчен генә түгел, һәр сабый бала өчендә газиз һәм кадерле булырга тиеш.Туган якның табигате, аңа бәйле кызыклы фактлар, аның тарихы, халыкның көнкүреше, гореф-гадәтләре, милли йолалары балаларга белем һәм тәрбия бирүдә зур роль уйный.

Милли төбәк компоненты халык һәм милләт үзенчәлеген, мәдәниятен һәм рухи дөньясын, телен һәм тарихын, табигый-географик мохитен, традицияләрен чагылдырган укыту материалын берләштерә.Укучы үзе яши торган төбәкнең табигатен, аның үзенчәлекләрен, халкын, традицияләрен, мәдәниятен, тарихын яхшы белергә тиеш.

Әлбәттә, һәр төбәкнең үзенең мактанычы, горурлыгы була. Әйтик, Актанышлар - Минтимере, Арчалар – Тукае, Әлкиләр – Нәби Дәүлие, Сарманнар – Илһамы белән горурлана. Безнең Нурлат та мондый халәттән мәхрүм түгел. Аның Кизләү, Күлбай Мораса кебек тарихи авыллары, Кариев кебек талантлары, академик Галиуллиннары бар.

Районыбызның йөзе - ул аның талантлары. Укучылар районыбызның йөзек кашлары турында күбрәк мәгълүмат тупларга тиешләр.

Проект Нурлат районының оешу тарихы, Кизләү мәдрәсәсенең тарихы белән танышу, Утыз Имәни иҗатының үзенчәлекләре, Нурлат төбәгенең гореф-гадәтләре һәм әби-бабаларыбызның йолалары, “Җиде бабаңны беләсеңме?”, батырлык эзсез югалмый (сугыш геройлары), район матбугаты тарихы. ”Дуслык” газетасы үсеше, районыбыздан чыккан күренекле кешеләр (һөнәр ияләре,хезмәт алдынгылары), данлыклы шәхесләребез. Районнан чыккан язучылар һәм сәнгать әһелләре белән таныштыру, язучы, академик Т. Галиуллин, җыр һәм моң сәнгатендә С.Рәхмәтуллинның, С.Миңнехановның туткан урыннары, Г.Сәгыйров иҗаты белән танышу, "Өлешемә тигән көмешем” Җирле шагыйрә – Ф.Мөхәммәтова иҗаты, “Узып китмә минем тукталышны”. Җирле шагыйрә –С. Нуруллина иҗаты, “Кешеләргә әле кирәк мин”. Җирле шагыйрә –М.Хәбибуллина иҗаты, театр яктылыкка, нурга илтә, батырлык эзсез югалмый дигән темаларны үз эченә ала.

Бу проект Нурлат районы укытучыларына түгәрәк эшен оештыру өчен, тема һәм лекция материаллары, кичәләргә сценарияләр белән бергә әзер курс тәкъдим итә.

Алга куелган проблема өстендә даими һәм эзлекле эшләү эшемдә уңай нәтиҗәләргә китерә. Укучыларым республика һәм регионара үткәрелгән фәнни-эзләнү конференцияләрендә, әдәби конкурсларда призлы урыннар яулыйлар, татар теле һәм әдәбияты буенча югары уку йортларына укырга керәләр, республиканың төрле мәктәпләрендә ана телен укыталар. Балалар иҗат иткән әсәрләр республиканың төрле газеталарында басылып тора. Даими рәвештә безнең укучылар конкурс эшләрендә җиңеп чыга. Туган тел һәм әдәбияттан өлгермәүчеләр юк. Укытуның сыйфаты 88% тан югары.

“Татар телендә төп гомуми белем бирү оешмаларының югары сыйныф укучылары өчен дәрестән тыш чаралар үткәрү үзенчәлекләре: түгәрәк эшчәнлеге” дип

аталган махсус проектым татар теле буенча укучыларда

мөстәкыйль эшли белү күнекмәләре булдыруга, осталыкларын камилләштерүгә, укучыларның әдәбият буенча белемнәрен тулыландыруга зур ярдәмлек ролен үтәр, республиканың башка мәктәпләрендә дә сынау узар дип өметләнәм.

Файдаланылган әдәбият:


1. Ахунов Г. Эшләгән эше таулар кадәр // Галиуллин Т.Н. Шигърият баскычлары: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – К.: Мәгариф, 2012. – 226 –229 б.

2. Галиуллин Т. “Мәкер”, Татарстан китап нәшрияты. 2008.

3. Галиуллин Т. “Төнге юллар”, Казан, Матбугат йорты китап нәшрияты. 2012.

4. Галиуллин Т. “Элмәк”, Казан, Татарстан китап нәшрияты. 2013.

5. Җәләлиев Ш. “Акыл яшьтә түгел-башта” Мәгариф- №9, 2014.

Мөхәмматова Ф. “Ышаныч, Өмет, Мәхәббәт”, Казан, “Идел-пресс”, 2016.

6. Нәбиуллина Г.Ә., Гыйләҗева Л.Г.,Дөньяда сүзем калыр.- Казан: Татар. кит. нәшр., 2012.-495б.

7. ”Нурлатым-нурлы атым”.”Школа” Казан, 2016

8. Нурлат тарихы турында материаллар тупланмасы. ”Дуслык” газетасы, октябрь, 2014.

9.”Нурлат: еллар һәм йөрәкләр бәйләнгән”. Нурлат районы оешуга 100 ел тулу уңаеннан чыгарылган брошюра. Нурлат, 2012.

10. Сәгыйров Г. Идел-Пресс, 2014.

11. Советлар Союзы Геройлары. Якташларыбыз. Татарстан китап нәшрияты, 1990.

12. Татар әдәбияты тарихы.1 том. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 2016.

13. Хәйруллина С. “Күзләремнән язлар көнләшә”Казан, “Рухият” нәшрияты, 2014.

14. ”Яңа үрләр яулаганда”: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. Казан, Татарстан китап нәшрияты – 2012.



Хәзерге заман кешеләрдән һәрвакыт эзләнүне, белемен арттыруны таләп итә. Укытучылар да, укучылар да моңа әзер булырга тиеш. Минемчә, әлеге замана таләбенә буйсыныр өчен без укучыларыбызны эзләнергә, үзләренә табарга, тапканны системага салырга, тупларга, аннары башкаларга тәкъдим итәргә, тормышта урынлы кулланырга өйрәтергә тиешбез. Иң беренче, әлбәттә, укытучы үзе һәр нәрсәнең асылына төшенергә тиеш. Чыннан да, уку-укыту эше фәнни әзерлек, күпьяклы эрудиция, киң күңеллелек һәм түземлелек таләп итә. “Кырык бакча” китабында: “Әгәр кемне дә булса нәрсәгә дә

булса өйрәтергә телисең икән, иң элек син үзең бу эшне бик яхшылап өйрән, сиңа карап башкалар да бу эшкә өйрәнергә теләр,” – дип язган галим К.Насыйри. Әйе, тормыш үзгәрә, мәгарифнең дә яңа шартларда яшәргә сәләтле кеше тәрбияләүдә җаваплылыгы арта. Минемчә, белем бирүнең сыйфатын үстерү юлы буларак проектлау ысулы мөһим урын алып тора.

Хезмәтем 3 өлештән тора:

1. Нәрсә ул проектлар методы?
2. Тәҗрибә уртаклашу
3. Киңәшләр.

1. Нәрсә ул проектлар методы?

Башта проект эшчәнлегенең асылына төшеник, аңа хас билгеләрне билгелик, нинди максатларга ирешә алуыбызны ачыклыйк. Проект методы – нинди дә булса проблеманы өйрәнү һәм гамәли нәтиҗәсен күрсәтү өчен укучыларның мөстәкыйль эшчәнлегенә нигезләнгән укыту методы ул. Әлбәттә, проект методы укучыга мөстәкыйльлек бирә, иҗади эшкә мөмкинлек тудыра, үз хезмәтен башкаларга тәкъдим итәргә шартлар булдыра. Укытучы киңәшче, юнәлеш бирүче вазыйфасын үти.

Татар теле һәм әдәбияты укытканда түбәндәге проектларның төрләрен язарга мөмкин: тикшеренү, иҗади, гамәли юнәлешле, предметара.

Проект ысулын куллану – ул алган белем һәм күнекмәләрне системалаштыру, мөстәкыйль эшчәнлек кору, фәннәр арасында бәйләнеш табу, кызыксындырган проблемаларны билгеләү, чишү юлларын табу, эш нәтиҗәсен тәкъдим итә алу.

Проект язуның төп өлешләре:

1. Тема сайлау (Теманың актуальлеге, эшнең максаты һәм бурычлары , өйрәнү объекты билгеләнә,.)
2. Темага бәйле рәвештә материал туплау (Теоритик һәм матур әдәбият туплау.Укучыларга төп әдәбиятны күрсәтергә кирәк, эш барышында ул үзе дә тагын кирәкле язмалар туплаячак. Бу этапта якынча план күзаллана.)
3. Темага кагылышлы теоритик материал өйрәнү ( Темага караган фәнни-теоритик әдәбиятны өйрәнүне тарихи хронологик тәртиптә түгел, ә “кире тәртиптә” алып бару яхшырак. Иң башта соңгы елларда чыккан әдәбият белән танышырга, аннары эзлекле рәвештә, элегрәк еллардагы чыганакларны өйрәнәсең. Нәтиҗәдә искергән хезмәтләргә бүгенге көн югарылыгыннан торып бәя бирергә мөмкинлек ачыла, теманың кайсы яклары әле һаман да тиешенчә яктыртылмаганлыгы яки бәхәсле булуы ачыклана. Алда кулланырга кирәк булачак фикерләр, цитаталар язып алына.
4. Эзләнү-тикшеренү методларын һәм алымнарын билгеләү.
5. Барлык тупланган материалны өйрәнү, системага салу ( уку , анализлау, картотека төзү, классификацияләү, экспериментлар үткәрү, теоритик материалга нигезләнеп гомумиләштерүләр ясау һ.б.)

Проект эшенең төзелеше:

1. Титул бите
2. Эчтәлек
3. Кереш
4. Төп өлеш
5. Йомгаклау
6. Файдаланылган әдәбият исемлеге

7. Кушымта(булган очракта)

Укучыларны эзләнү-тикшеренү белән шөгыльләндерә алу бик зур мөмкинлекләр ача, укучыларның сөйләм телен, иҗади сәләтен үстерергә ярдәм итә. Әдәбият белән кызыксындыруда аеруча нәтиҗәле. Беренчедән, мондый укучылар китапларны күпләп укый башлыйлар, чөнки әдәби әсәр аның эзләнү эшендә төп чыганак булып хезмәт итә. Укучы китап авторының башка әсәрләрен алып укый, чагыштыра, бу темага язылган башка авторларның да хезмәтләрен, әсәрләрен эзли, иҗади фикерли. Икенчедән, укучының төрле сүзлек, тәнкыйди материаллар белән эшләү күнекмәсе арта. Укучыларда мондый күнекмәләр булдыруга игътибарны көчәйтергә кирәклеге ачык. Торган саен күбәя барган фәнни мәгълүмат эзлекле рәвештә эшли белүне таләп итә.

"Табу өчен, нәрсә эзләгәнеңне белергә кирәк!" – дип язган якташ шагыйребез Ш.Галиев. Әлбәттә, проект эшенә керешкәнче, тема һәм максатын дөрес итеп сайларга кирәк. Нәрсә эзләргә кирәген белгәч, шул ноктадан башлап китәсең дә икән. Бусы булды бер. Икенчедән, тапкан материалның иң кирәклесен генә аерып алу. Бу – гаять зур көч таләп итүче эш, чөнки материалны берләштереп, кыскартып, төп фикерне чыгара барырга кирәк. Менә шул чыга барган төп фикерләр укучыга омтылыш бирә, иҗат дәрте уята. Биредә цитаталарга да игътибар итәргә кирәк, төп фикерне ачуда аларның әһәмияте искиткеч зур. Килеп чыккан нәтиҗәләрне бик кыска формада дәлилләргә кирәк. Бусы пректны яклау була инде.

2. Тәҗрибә уртаклашу

20 еллык укыту тәҗрибәсеннән чыгып, укучылар белән эшләүнең ысуллары күп булуын ачыкладык, алар һаман үзгәрә һәм камилләшә тора. Папкаларны барлап чыктым һәм мондый нәтиҗәгә килдем: проект эшчәнлеген ун ел алып барылган, шактый бай мирас җыелган икән бит...

Иң беренче итеп, моннан 11 ел элек, 2010 елда, Кояш Тимбикованың иҗади мирасын өйрәнүгә багышланган I республикакүләм фәнни тикшеренү укуларына язылган "Кояш баласы" исемле хезмәт туплап чыгуыбыз истә калган. Татар теле бүлмәсендәге бөтен иске газета-журналларны актарып, материаллар туплаганыбызны хәзер дә хәтерлим. Апас районы Дәвеш төп гомуми белем бирү мәктәбенең 8нче сыйныф укучысы Җәләлиева Әдилә Ирек кызы белән эшләдек. Аны якларга Чистайга кадәр баруыбыз, урын алып кайту онытыламы соң?!. Менә шуннан башланды проект эшчәнлеге... Елдан ел камилләшә генә барган, укучылары гына алышынгандыр дип уйлыйм. Укучыларым катнашып, ел саен урыннар да алалар, бай материал да туплыйлар. Аннары 2011 елда 7 сыйныф укучысы Хөсәенова Рүзилә белән " Каюм Насыйри – күпкырлы шәхес" дигән проект яздык. Шул ук укучы белән 2012 елда "Мин авылны сайлыйм" II республикакүләм проектлар бәйгесендә катнаштык. "Алтыным син, көмешем, туган җирем – Дәвешем" хезмәте җыентыкта басылды.

2013 елда "Туган телем – шагырьләр теле" республикакүләм фәнни-эзләнү конференциясенә 8нче сыйныф укучысы укучысы Загидуллин Илназ Наил улы белән "Шәүкәт Галиев мәктәбе" исемле хезмәтен туплап чыгардык.

2014 елда Ибраһим Хәлфин истәлегенә багышланган IX республика фәнни-эзләнү укучылар конференциясенә 9нчы сыйныф укучысы Загидуллин Илназ Наил улы белән "Ибраһим Хәлфин – татар грамматикасына нигез салучы галим фәнни хезмәт" дигән проект эше белән катнашып, призлы урын да алдык.

2016 елда шагыйрь Әхмәт Рәшитнең 80 яшьлек юбилеена багышланган “Кояшлы ил” республикакүләм конференциясенә язылган “Талантлы син, Кеше туганым” исемле хезмәтне Дәвеш төп гомуми белем бирү мәктәбенең 3нче сыйныф укучысы Хөсәенова Сөмбел Илнаровна белән язган идек. Икенче дәрәҗә диплом белән бүләкләндек.

Шул ук укучы белән “Иманга дәшеп халыкны, Яңгырый моңлы азан...” дигән хезмәт белән “Шәҗәрәләр – нәсел агачы” VI регионара фәнни-гамәли конференциясендә катнашып, икенче урын алдык.

Күпме көч түгеп язылган хезмәтләр... Шунысы куанычлы: әлеге хезмәтләрнең күбесе җыентыкларга кертелгән, китап булып тупланган, димәк, югалмый, киләчәк буыннарга да тапшырылачак. Укучылырым белән генә түгел, үзем дә XV республикакүләм Ризаэддин Фәхреддин укуларында

“Гаиләнең бәхете – тәрбияле хатын кулында” дигән хезмәтем белән катнашып, призлы урын алдым. “Якташларым-горурлыгым” проектын грант кысаларында мәктәптә алып бардым. Хезмәтләр шактый, бары югалмасын иде. Үз укучысын, кызыксынучысын тапсын гына...

3.Киңәшләр

Эш тәҗрибәмнән чыгып, сезгә түбәндәгеләрне тәкъдим итәм:

1. Эшнең планын төзеп куярга.
2. Мәгълүмат табарга өйрәтергә.
3. Шуннан иң кирәген алырга, язарга.
4. Башкаларга тәкъдим итәргә өйрәнергә.
5. Эшне дәвам итәргә, тукталмаска.
6. Һәр проектның нәтиҗәсе, продукты була бит, шуларны тупларга.
7. Хезмәтең белән башкаларны да кызыксындырырга.
8. Ирешкәннәр белән тукталып калмыйча, һәрвакыт яңаларын эзләргә.

Эшләү барышынданиләргә игътибар итәргә соң?

1. Проектны тормышка ашыру планына

Беренче этап. Төрле чыганаклардан проект өчен мәгълүмат туплау. Буклет, презентация төзү. Дәресләргә дидактик материал әзерләү. Группада эшне бәяләү, укучының үз-үзен бәяләү кәгазьләрен төзү. Укучыларның презентацияләрен бәяләү өчен критерийлар билгеләү.

Төп этап. Проект буенча беренче дәрестә презентация күрсәтү. Буклетларны тарату. Дәрестә хәл ителергә тиешле проблема һәм уку мәсьәләләрен билгеләү. Эзләнү эше өчен темалар билгеләү. Мәгълүмат алу өчен чыганакларны ачыклау. Проектны тәкъдир итү алымнарын билгеләү, укучыларны проект эшенең формалары белән таныштыру. Төркемнәр формалаштыру. Укучыларның төркемнәрдә проблема өстендә эшләве. Эш нәтиҗәләрен презентацияләү, анализлау, киңәшләр бирү.

Йомгаклау этабы. Проект темасы буенча нәтиҗәләр. Укучылар чыгышы. Алдан бирелгән критерийлар белән укучылар иҗатын анализлау, бәяләү.

Көтелгән нәтиҗә

1.Проект тәмамлангач, укучылар татар теленнән мәгълүматлар табу буенча проект эшендә катнаша алалар һәм тапкан мәгълүматларны бәялиләр;

2. Һәр төркемнең лидеры коллектив алдында чыгыш ясый, аны яклый;

3. Проект буенча презентация эшләнә;

4.Проектта катнашучы һәр укучының шәхси, интеллектуаль, аралашу осталыгы күрсәтелә;

5. Мәгълүматның күләменә,катнашучыларның санына карап, презентация үткәрү өчен тиешле вакыт күләме билгеләнә;

6.Уңышлар һәм чишелмәгән проблемаларны күмәкләп ачыклана, анализлана;

7.Киләчәктә проектны дәвам итү мөмкинлекләре, юллары билгеләнә;

Эш формалары

Проект эшендә кулланырга мөмкин булган эш формалары: буклет ясау, газета чыгару, терәк схема ясау, таблица тутыру,брошюра ясау, электрон презентация видероликлар эшләү. Проект методы белән оештырылган педагогик процесска хас сыйфатлар: укучы эшчәнлеге тормыш тәҗрибәсенә, җәмгыять яшәешенә бәйле проблемаларны хәл итүгә буйсына; проектлар мәҗбүри рәвештә уңай нәтиҗә бирә, тискәре нәтиҗәле проектлар эшләнми.

Проектны яклау процессы катгый алгоритмга буйсына, ул проект асылыннан чыгып, укучылар тарафыннан төзелә. Укучылар эш барышында кирәкле информацияне генә эзлиләр һәм үзләштерәләр.

Язмамны татар классик язучысы, тел һәм әдәбият галиме, танылган педагог-методист Г. Ибраһимов сүзләре белән тәмамлыйм: “Күп белдерүгә караганда да, аз белдереп, эзләнү орлыгын салу һәм эзләгәнен үзе табарга юллар күрсәтү – мөгаллим бирә ала торган хезмәтләрнең иң кадерлесе, иң зурысыдыр. Бу – мәңгелек бер нур, һичбер вакыт сүнми, арта барган саен арта, ниһаять, адәмнең рухын бөтенләй яктыртып җибәрә торган нурдыр.”

Укытучы өчен әдәбият исемлеге:

1. Заһидуллина Д.Ф. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. - Казан: Мәгариф, 2000.

2. Заһидуллина Д.Ф., Закирҗанов Ә.М., Гыйләҗев Т.Ш.Татар әдәбияты.Теория, тарих. Казан: Мәгариф,2004.

3. Җәләлиев .Ш. Татар халык педагогикасы. – Казан: Мәгариф, 2007.

5.Трофимова С.М., Галиева Г.Н. Татар теле һәм әдәбиятын укытуда проектлар методы.Казан, 2015.

**Халимова Г.Җ.,**
**Лениногорск шәһәре, 4 урта мәктәбе**

## РУС МӘКТӘПЛӘРЕНДӘ ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘНҮ: ПРОБЛЕМАЛАР, ЧИШЕЛЕШЛӘР

Бүгенге информациягә бай , минут саен меңләгән яңалык булып торган дөньяда яшәү һәм үз-үзеңне югалтмау, адашып калмау бурычы һәрберебез алдында тора торган бурычларның берсе. Кемдер бу бурычны үти ала, ә кем өчендер ул үти алмаслык авыр . Шуның өчен хәзерге заман мәктәбе каршына дөньякүләм интегралда яши һәм үсә алырлык яңа шәхес формалаштыру таләбе куела. Бүген тормышта укыту һәм тәрбиянең яңа төрләрен эзләү, аларны куллану кирәклеге бик нык сизелә. Бүгенге укытучылар,

класс җитәкчеләре мәктәптән үз-үзенә ышанган, мөстәкыйль эш итә торган, көндәшлеккә сәләтле, дөрес аралашу серләрен белүче, рухи дөньясы бай, иң матур кешелек сыйфатларына ия булган чыгарылыш сыйныф укучысы әзерләп чыгарырга тиеш .[1:11] Күргәнебезчә, таләпләр бик зур. Бу максатны тормышка ашыру өчен, укытучыларның һөнәри осталыгын арттыру, аларны яңа педагогик технологияләр, метод һәм алымнар белән эшләргә өйрәтү, шуның нигезендә укучыларга белем һәм тәрбия бирүнең сыйфатын күтәрү өстендә эшләргә кирәк . Бүгенге көндә югары уку йортларында хәзерге заман укучысы белән кулга-кул тотышып эшли белүче , балаларны телнең серле дөньясына алып керүче яшь кадрлар әзерләүдә нинди дер тотрыксызлык сизелә.

Ни өчен уку чорында укучыларда белем алуга мотивация кими соң? Барлык балалар да мәктәпкә укырга дип киләләр һәм укырга телиләр. Тора-бара балалар белән нәрсә була, нигә бала өчен уку процессы авыр йөккә, кызыксыз эшкә әйләнә? Моңа кем гаепле, нишләргә? Иң мөһиме: белем алуга кызыксынучанлыкны ничек арттырырга? Бу сорауга җавапны мин татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак, телне белү, аралашу культурасы булдыру белән бәйләр идем. Аралаша белгән кеше , коммуникатив сәләтләре көчле укучы полилигваль культураныбик җиңел кабул итәчәк. Төрле тел белү укытуныә практик юнәлгәнлеген булдыра. Күн кенә ата-аналар үзләренеә балалары белән Төркиягә ял итәргә бара. Татар телен белүче кеше рәхәтләнеп төрекләр белән аралаша алуын исбатладым мин үзем өчен. Тере аралашуны скайп буенча да оештырып карадык. Бу , билгеле, укучыларның аралашу теләген арттыра

Барыбыз да беләбез: 2017 нче ел ана теле могаллимәсе каршына зур проблемалар куйды. Укыту планыннан алып ташланган дәресләр саны күп кенә укытучыларны тәртәдән чыгарып, гаҗиз калдырды. Нишләргә ? дигән сорау бөтен республика татар телчеләре алдына куелды. Ни генә булмасын укыту систмасында тәҗрибәсе булган укытучылар, үзләренең юлыннан читкә тайпылмады. Без бу проблемага җавапны үзебездән эзләдек. Чыннан да, күп кенә галимнәр дәреслекләрне дә бетереп ташлады, УМК ларны да үзгәртергә тәкъдим ясады. Минем уйлавымча, дәреслекләр, аларның эчтәлеге, материалның бирелешендә хата юк. Ә менә укытучыларның шул дәреслек белән дөрес куллана белмәвендә бит безнең бәла. Дәреслектә язылган һәр күнегүне эшләп бетерергә дигән максатны минем бер җирдә дә укыганым юк. Ә менә коммуникатив , аралашу юлларын, ысулларын кулланып укыту турында һәрдаим сөйләнә.

Мәктәпнең төп укыту формасы - дәрес. Дәрес, аны планлаштыру һәм үткәрү - бу укытуның һәр көнне аңлап, уйлап башкара торган эше. Дәрес - ул укытучының шәхси һәм һөнәри “көзгесе”, иҗади остаханәсе. Һәрбер дәрестә укытучының педагогик системасын һәм нәтиҗәләрен күрергә була. Дәрестә яңача ачышлар туа, экспериментлар үткәрелә, проблемалар чишелә, хаталар ачыклана, иҗади эзләнүләр алып барыла, уңышлы нәтиҗәләр ясала.
Дәрес ул - укучы өчен үсеш вакыты: кызыклы һәм мавыктыргыч “Белем дөньясына” сәяхәт итү, фән баскычларыннан биеклекләргә менү, аның серле һәм таныш булмаган сукмакларыннан бару. Укытучы һәр дәресенә зур әзерлек белән керә, кечкенә шәхесләрнең интеллектуаль, социаль, психик, физик һәм рухи сфераларын үстерүгә зур көч куя һәм махсус шартлар булдыра.
Нәкъ шушы дәресләрнең ролен , әһәмиятен югалтмыйсы иде бит. Безнең ата-

аналарыбыз татар теленә ышанычны бөтенләй бетермәде бит. Бүгенге көндә мәктәп күләмендә 74 % ата-аналар һәм укучылар татар телен өйрәнүне ана теле дәрәҗәсендә сайлый. Димәк, кызыксынуны югалтмас өчен, безгә җиң сызганып эшләргә кирәк. Укучыларның татар теле өйрәнү серләренә төшендерү класстан тыш чараларда да башкарыла . Һәркем өчен туган ягы бик кадерле . Туган туфрак кешене иманлы итүдә зур роль уйный. Безнең як даһи шәхесләргә бик бай як. Шуның өчен дә тел өйрәтүнең бер чарасы итеп " Әдәб мирас" музее эшчәнлеген алабыз . Шул кысаларда өлкән класс укучылары белән берлектә "Утыз Имәни мирасын укыту – тәрбия процессында куллану" дигән проектны тормышка ашыру өстендә эшлибез

Халкыбызның алдагы көне, язмышы бүгенге балаларны, яшьләрне тәрбияләү белән тыгыз бәйләнгән. Укыту-тәрбия эшендә катлаулы, әлегә хәл ителмәгән мәсьәләләр шактый күп. Шулардан балаларны гаиләдә тәрбияләү, әхлаклылыкка өйрәтүне аерып әйтергә кирәк.

Хәзерге вакытта балаларда милли үзаң тәрбияләү, татар теленә мәхәббәт уяту, рухи яктан бай булган шәхес тәрбияләү аеруча игътибарга лаеклы проблемаларның берсе. Бу проблемаларны чишүдә татар халкының күренекле шагыйре, энциклопедик белемле укымышлысы, галиме Утыз Имәни әсәрләрен өйрәнү зур әһәмияткә ия. Мәктәп дәреслекләрендә аның әсәрләрен өйрәнүгә урын аз бирелә. Ләкин ике гасырдан артык элек яшәгән, күпкырлы эшчәнлек башкарган кешенең әдәби мирасын өйрәнү безнең көннәрдә дә актуаль. .

Һәр әсәрендә ул әдәп-әхлак тәрбиясенә мөрәҗәгать итә. Бүгенге көндә күңел сафлыгы, олыларны олы итү, кечеләргә үрнәк күрсәтү кебек сыйфатлар югалып барганда, мәңге искермәс мәрхәмәтлелек, изгелек, кешелеклелек, олы йөрәклелек сыйфатларын тәрбияләүне пропагандалый икән аның әсәрләре, димәк, алар бүген дә безгә кирәк.

Шуны истә тотып, өлкән класс укучыларына Утыз Имәни иҗатын өйрәтү буенча электив курслар үткәрү өчен программа төзелде..

Программа укучыларның сәләтләрен ачыкларга, төрле традицион булмаган дәрес формалары аша дөрес сөйли, аралаша, фикерләрен аңлаешлы, эзлекле итеп әйтә белүнең киләчәк тормышта кирәк булуына инандыру өчен укытучыга зур ярдәмлек булып тора.

Программада төрле эш формалары бирелде: конференцияләр, диспутлар, әдәби кичәләр, очрашулар, лекцияләр. Күләмле, кирәкле мәгълүматлар сыйдырган дисклар, төрле презентацияләр куллану курсның эчтәлеген тагын да баета. Бу проект чикләрендә 4 мәктәптә татар әдәбияты ,татар теле, дәресләрендә Утыз Имәни иҗатын өйрәнү конкретлаштырылды. Класс сәгатьләрен үткәргәндә аның әсәрләрен куллану буенча методик рекомендацияләр әзерләнде

УФО да тикшерелгән эзләнү эшләре, музей эшчәнлеге укучыларның иҗади активлыгын арттыра
Бу проектны тормышка ашыруда ата-аналар белән эшчәнлекккә аерым урын бирелә. Шәһәрдә яшәүче татарларның да үз телендә иркен аралашканнары чагыштырмача күп түгел. Чөнки күбесе эш урыннарында рус телендә аралаша, җәмәгать урыннарында, транспортта, урамда да, кагыйдә буларак, рус телендә сөйләшә. Олы яшьтәге һәм урта буын татар кешеләре гаиләдә күбрәк үз телләрендә сөйләшсә дә,

шәһәр яшьләре һәм балаларының күбесе өйләрендә дә русча сөйләшә, русча аралашалар. Әлбәттә, балага туган тел иң беренче чиратта гаиләдә сеңдерелә. Гаиләдә, аннан соң балалар бакчасында, башлангыч мәктәптә туган телендә тәрбияләнгән бала ана телен инде онытмаячак, ди белгечләр. Аннан соң, ана телендә тәрбияләнгән бала тәртиплерәк, әхлаклырак, туган җанлырак та була яшь ата-аналар белән эшне оештыру " Сердәш" клубы төзүдән башлана.
-Яшь аналар өчен "Сердәш" клубы эшчәнлегендә дә Утыз Имәни әсәрләре еш кулланыла

**- КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ**


**I. Норматив-хокукый документлар**

1.1 "Төп гомуми белем бирүнең федераль дәүләт стандарты". РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы, 2010.

1.2 Хәйдәрова Р.З, Малафеева Л.Р. Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы, 2013.

**II. Фәнни һәм методик әдәбият**

2.1 Зайцева М.В. Мотивация и некоторые пути её повышения. М., ИД "Первое сентября", 2003. – с. 23

2.2 Камаева Р.Б. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә яңа педагогик алымнар. – К(И)ФУ АФ нәшрияты, 2012.

2.3 Пассов Е.А. Коммуникативный метод обучения иноязычному говорению. Москва, Просвещение, 1991.

2.4 Фәтхуллова К.С, Юсупова А.Ш., Денмөхәммәтова Э.Н. Татарча сөйләшик. Казан: Татар.кит.нәшр.,2015.

2.5 Хәйдәрова Р.З.Рус телендә сөйләшүче укучыларны татар теленә өйрәтү өчен төзелгән укыту-методик комплекты белән эшләү үзенчәлекләре. "Мәгариф", №10, 2014.

2.6 Хәйдәрова Р.З. Федераль дәүләт белем бирү стандартларына күчү шартларында татар теле һәм әдәбияты укытуда яңа технологияләр, 2013.

2.7 Шәймәрданова Н. ФДББС шартларында татар теле һәм әдәбияты укытучыларының методик компетентлыгын камилләштерү. "Мәгариф", №3, 2015.



**Хайруллина Ч.А., учитель русского языка и литературы**
**МБОУ «Муслюмовская гимназия»**


## ИСПОЛЬЗОВАНИЕ ВИРТУАЛЬНОЙ ОНЛАЙН-ДОСКИ PADLET В ПРОЕКТНОЙ ДЕЯТЕЛЬНОСТИ


***Аннотация:*** В статье рассматривается актуальная на сегодняшний день проблема сетевого взаимодействия обучающихся в образовательном процессе. В своей работе автор акцентирует внимание на возможности применения виртуальной доски Padlet, также дает практические рекомендации по созданию такой доски. Автор приводит в качестве примера один из созданных проектов обучающимися и приходит к выводу, что

использование доски Padlet продуктивно в процессе урочной и внеурочной деятельности.

***Ключевые слова:*** виртуальная доска Padlet, групповая работа, проектная деятельность.

В основе стандартов второго поколения лежит деятельностная парадигма образования, которая определяет в качестве цели образования развитие личности учащихся на основе освоения универсальных способов деятельности. Это означает, что для развития ребенка необходимо организовать его деятельность, мотивировать на проявление инициативы и самостоятельности, создать условия, в которых становится возможным формирование определенных компетенций. Таким образом, необходимо создать, так называемую, «развивающую среду».

Современные учащиеся – цифровое поколение, живущее в эпоху мультимедийных технологий. Интернет стал для них самым большим коммуникационным инструментом и изменил способ, с помощью которого мы привыкли взаимодействовать в прошлом. Ежедневное использование сайтов социальных сетей стало важной частью жизни современных подростков. Сеть Интернет - настоящий мир для подростков, который позволяет им делиться своими идеями и мнениями, а также стать частью настоящего сообщества. Поэтому в современном образовании меняется позиция педагога: он перестает быть единственным источником знаний.

В этой связи задача любого педагога – помочь учащимся стать активными участниками образовательного процесса, сформировать у них потребность в постоянном поиске дополнительных знаний и интересных решений. Другими словами, создать такую модель учебного процесса, которая позволяла бы раскрывать и развивать творческий потенциал учащихся.

Среди огромного числа таких моделей я предлагаю рассмотреть онлайновый сервис «Padlet» Этот сервис можно использовать на уроке и во внеурочной деятельности обучающихся при работе над проектом. Развивающая среда, похожая на социальные сети, поможет повысить мотивацию учащихся и эффективность процесса их обучения. А учителю позволит превратить школьный учебный проект в маленькую модель социальной сети.

Что же такое «Padlet»? «Padlet» – это интерактивная доска или стена, которая может быть создана учителем или учеником. Стена всегда имеет определённую тему, согласно которой и происходит наполнение стены. На стену можно помещать аудио и видеофайлы, фото, документы. Стена состоит из окошек, каждое из которых активно и содержит загруженный материал. «Padlet» поможет создать доску объявлений, обсуждения, рассуждения, головоломки, сбор отзывов.

Доску Padlet создать достаточно легко: сначала педагог регистрируется на сервисе Padlet.com, а затем создает свою доску (которая иногда называется стена Padlet), дает ей название, устанавливает фон, размещает необходимые элементы.

На интерактивной доске Padlet могут размещаться заметки, тексты, всевозможные изображения, фотографии, видеофайлы (в том числе с веб-камеры любого мобильного устройства) и ссылки на внешние ресурсы. Возможно перемещение элементов, увеличение или уменьшение их, внесение записей на доску, настройка фонового изображения и организация совместной деятельности с другими пользователями. По

мере готовности доски, ею можно поделиться ей в социальных сетях, встроить ее в сайт, экспортировать в различных форматах, распечатать, и даже создать QR-код.

В бесплатной версии сервис Padlet позволяет создавать (на данный момент) 3 бесплатные доски. Обучающиеся могут принять участие в дополнении открытой педагогом фотогалереи на доске Padlet без их регистрации в сервисе. Ссылку можно отправлять любым способом.

Осуществлять загрузку файлов и просматривать посты на «стене» можно в любое время, с любого гаджета, который имеет доступ в Интернет. Таким образом, виртуальная стена живет и расширяется. Работа над проектом начинается с постов учителя, которые будут дальше пополняться постами учащихся по теме проекта. Сервис Padlet позволяет демонстрировать эти посты на уроке в режиме презентации. Эти слайды остаются на виртуальной стене, и ученики всегда могут вернуться к презентации учителя и пересмотреть ее снова, скачать необходимые документы или использовать как хранилище информации.

Перед началом работы над проектом «Татарстан – Родина моя» (https://padlet.com/rmorus2020/s2l4ghlldow3me7s), посвящённом Году родных языков и народного единства в Республике Татарстан, класс разделился на 4 исследовательские группы, перед каждой из которых была поставлена определенная исследовательская задача. Каждой группе было отведено на виртуальной доске свое место, куда они должны были прикрепить результаты своих исследований в любом удобном для них виде: слайд, видео, ссылка или текст.

Проект состоит из семи разделов (при желании можно добавить еще разделы):

1. «Год родных языков и народного единства в Республике Татарстан». Здесь прикреплены указ президента РТ Р.М.Миннеханова об объявлении 2021 года в РТ Годом родных языков, логотип года.
2. «Родной Татарстан». В этом разделе можно найти информацию о республике и красочные иллюстрации.
3. «Республика моя родная, процветай». Здесь можно прочитать стихи Татарстане.
4. «Татарстан – моя родина». На территории современной республики проживает Большое количество народностей, поэтому этот раздел посвящен многонациональному Татарстану.
5. «Татар теле – Тукай теле». Г. Тукай считается одним из основоположников татарского языка, он один из первых написал о его выдающейся роли. Этот раздел учащиеся посвятили великому татарскому поэту.
6. «Праздники народов Татарстана». Данный раздел создан, чтобы расширить представление о национальной культуре татар, русских, марийцев и чувашей и познакомить с их народными традициями, обычаями и обрядами.
7. «Год родных языков в Муслюмово». Здесь можно найти информацию о том, как отмечают 2021 год в нашем районе и в нашей гимназии». Этот раздел будет пополняться в течение года.




Я считаю, что web-сервис Padlet является универсальным и простым в использовании инструментом и открывает широкие возможности для учителей любого предмета в плане интеграции новой технологии обучения с традиционными. Такой подход к организации образовательного процесса создает повышение активности учащихся, позволяет раскрыть их возможности и повышает качество обучения.

В заключение хочу отметить, что использование интерактивной онлайн-доски – неотъемлемая часть современного процесса образования. Виртуальная доска Padlet способствует формированию и развитию ИКТ-компетенций, расширяет возможности урока в условиях реализации ФГОС, и позволяет им быть равноценными участниками в проявлении творческих идей и создании общего креативного образовательного продукта.

***Хәмидуллина Рузилә Илзар кызы, П.С.Ханңин исемендәге Тәтеш 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбенең туган тел һәм әдәбият укытучысы***

## ТУГАН ТЕЛ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ПРОЕКТ ЭШЧӘНЛЕГЕН КУЛЛАНУ

Хәзерге вакытта дәресләрдә проект эшчәнлеген куллану актуальләште, бу исә , барыннан да элек, мәктәпләрнең компьютерлаштырылуына һәм балаларга мондый эш формасы кызыклы булуына бәйле.

Проект эшчәнлеге нигезендә укучыларның танып-белү күнекмәләрен үстерү, үз белемнәрен мөстәкыйль рәвештә конструкцияли белү, мәгълүмати киңлектә ориентлашу, аларның тәнкыйди һәм иҗади фикерләвен үстерү, күрү, формалаштыру һәм проблеманы хәл итә белү ята. Проблеманы хәл итүдә, бер яктан, төрле ысуллар, укыту чаралары куллану, икенче яктан – белемнәрне, осталыкларны интеграцияләү; төрле фән, техника, технологияләр, иҗади өлкәләрдән белемнәр куллану зарурилыгы күздә тотыла.

Эш тәҗрибәсе белән уртаклашканчы башта проектны структуралаштыруга тукталасым килә:

1. Проектны анык темасын сайлаудан , тибын, катнашучылар санын билгеләүдән башларга кирәк.

2.Алга таба билгеләнгән тематика кысаларында тикшерү мөһим булган проблемаларның мөмкин булган вариантларын уйларга кирәк. Проблемалар укучыларның үзләре тарафыннан укытучы бирү юлы белән чыгарыла (укытучы биргән сораулар, проблемаларны билгеләү һ.б.). Биредә "баш мие штурмы" ысулы урынлы.

3. Төркемнәр буенча бурычларны бүлү, тикшерү, мәгълүмат эзләү, иҗади карарлар буенча мөмкин булган методларны тикшерү.

4. Проектта катнашучыларның үзләренең шәхси яки төркемле тикшеренүе, иҗади бурычлары буенча мөстәкыйль эше.

5. Төркемнәрдә алынган мәгълүматлар турында (дәресләрдә , китапханәдә төркемнәрдә эшләү һ.б) фикер алышу.

6. Проектларны яклау.

7. Коллектив фикер алышу, экспертиза, бәяләү нәтиҗәләре.

Мин үз дәресләремдә иң беренче чиратта иҗади проектлар кулланам. 5-7 сыйныфларда татар теле һәм әдәбияты буенча проект биремнәре укучыларда кызыксыну уята, сәнгатьнең төрле өлкәләреннән белемнәрне интеграцияләү өчен шартлар тудыра.

Шулай итеп, 5 нче сыйныфта укучылар фольклорның кече жанрларын өйрәнгәндә «нәни китап»исемле шәхси мини-проект өстендә эшлиләр. Балалар үз китапчыклары өчен материал туплап, кечкенә фольклор жанрларын аерырга өйрәнәләр, аларның үзенчәлекләрен истә калдыралар. Балалар китаплар, интернет-ресурслар белән эшлиләр, әби-әниләреннән, әбиләреннән сорашып материал җыялар. Китаплар матур итеп бизәлә, тышлау, җыентыкның исеме, иллюстрацияләр уйлана. Кул эшләре хуплана. Балалар үзләренең ничек материал туплаулары, нинди авырлыклар очратулары, алар өчен бу эшнең файдалы булу-булмавы, нәрсә эшләргә өйрәнүләре, уйланылган әйберләрдән нәрсә эшләргә кирәклеге турында сөйлиләр. Барысы бергә сыйныфташлары арасыннан иң яхшы китапчык хуҗасын сайлыйлар.

7 нче сыйныфта, календарь-йола фольклорын өйрәнгәндә, балалар «календарь-йола җырлары»җыентыгын төзиләр. Бу төркемле кыска вакытлы проект. Балалар халык әсәрләренең бу төре, барыннан да элек, кыр эшләре циклы, шулай ук Сөмбелә, Нардуган, Нәүрүз,Сабантуй кебек мөһим ел бәйрәмнәре белән бәйле булуын беләчәкләр. Һәр төркем йола җырларының билгеле бер төре өстендә эшли. Балалар төрле чыганаклар белән эшли, йола җырларын башкару белән бәйле традицияләрне кыскача тасвирлап, материал туплыйлар, шул ук вакытта өлкән буын вәкилләренә мөрәҗәгать итәләр, календарь-йола җырларын белү-белмәүләре, аларны язулары белән кызыксыналар. Барлык төркемнәр дә җыентыкны ничек итеп бизәү турында фикер алышалар. Һәр төркем үзләренә тиешле битне үзе яза, аннан үз эшен тәкъдим итә, уңышлары һәм очраган кыенлыклар турында сөйли. Җыентыкны башка сыйныф укучыларына тәкъдим итәргә дә мөмкин.

Кыска вакытлы төркемле проектны үтәүнең тагын бер мисалы-юмористик газета чыгару. Ш. Галиев иҗатын өйрәнгәндә 5 нче сыйныф укучыларына «Язучылар елмая» бүлегендә үзләрен язучы ролендә сынап карарга, юмористик шигырьләр, хикәяләр язып карарга тәкъдим ителә. Балалар үзләре язган әйберләр турында фикер алышалар, уңай моментларны һәм килеп чыкмауны билгеләп үтәләр. Укучыны елмайту-бик авыр, ул һәрвакытта да килеп чыкмый. Шуңа күрә язучыга юмористик ситуацияләр тудырырга

мөмкинлек бирә торган кайбер алымнар белән танышу зарур. Кулъязмалар эшкәртелә, рецензияләнә, тикшерелә, газетаны рәсмиләштерү һәм аны мәктәп укучыларына – укучылар хөкеменә тәкъдим итү бара. Мондый эш барышында коммуникатив уку гамәлләре формалаша (сөйләм әсәрен төзи, сыйныфташлар белән аралаша белү, яхшы нәтиҗә алу максатыннан уртак эшчәнлек алып бару), танып-белү (язучының иҗаты турында алган белемнәрен, әдәбият белемен куллану); регулятив УУГ (эшне вакытында башкару, үзоешканлык һәм үзтикшерү, үзара контроль, хаталар төзәтә белү һ. б.), шәхси (үз мөмкинлекләрен аңлау, иҗади процесста катнашу теләге).

Әлбәттә, технологияне үзләштерүдә төрле авырлыклар белән очрашу котылгысыз.

Боларга, беренчедән, укытучының һәм укучыларның эш күләме артык күп булуы кирә. Проект эшчәнлеген оештыру эше укытучыдан җитди әзерлек эшен таләп итә, аның өчен күп вакыт кирәк. Проектны соңгы бизәү, проект папкалары төзү өчен дә вакыт җитми. Барлык оештыру эшләре еш кына телдән алып барыла, зур булмаган проектларны башкару максатлары һәм бурычлары шулай ук телдән әйтелә.

Еш кына укучылар билгеләнгән вакытка сыешмыйлар, биремнәрне үтәү озакка сузыла, танып-белү активлыгы кими, барысы да башланганны ахырына кадәр җиткерә алмыйлар.

Икенчедән, проект өстендә эшләүне оештыруда, Мондый дәресләрне әзерләүдә методик кыенлыклар бар. Өченчедән, һәрвакытта да проект эшчәнлегенә барлык укучыларны җәлеп итеп булмый. Әгәр төркем проекты булса, төркемдә, һичшиксез, эшлисе килмәгән укучылар табылачак, алар эшне җиңелрәк һәм азрак башкарачак.

Дүртенчедән, матди-техник тәэмин ителеш белән бәйле кыенлыклар бар. Проектларның күбесе мәгълүмат эзләүне, төрле чыганаклар белән эшләүне күздә тота, ә дәрестә кирәкле санаклар, Интернетка керү мөмкинлеге юк. Авыл җирендә кирәкле әдәбият табу кыен.

Бишенчедән, еш кына укучылар интернеттан файдаланып, аннан әзер эшне йөкләтеп алырга мөмкиннәр.

Күрсәтелгән кыенлыкларга карамастан, проект-ул кызыклы эшчәнлек төре. Бу технологияне куллануда укытучының кызыксынуы зур әһәмияткә ия, ул аны үз укучыларына тапшыра, аларны мәгълүмат алу һәм эшкәртүдә, иҗатта, аралашуда актив катнаша ала. Бу укучыларның мөмкинлекләрен ачарга, аларны хәзерге шартларда тормышка әзерләргә ярдәм итә.

Бүгенге көндә проект технологиясе белем бирү процессында үз позициясен алды. Проект эшчәнлеге барышында төрле төп компетенцияләр формалаша, алар астында заманча педагогикада бер-берсенә бәйле белемнәр, күнекмәләр, шулай ук укучыларның кыйммәтле ориентацияләр системасы һәм аларны кирәкле ситуациядә тормышка ашырырга әзер булган шәхеснең комплекслы үзлекләре күз алдында тотыла.Уку процессында укучыларның актив мөстәкыйль һәм инициативалы позициясе формалаша.Проект эшчәнлеге укучыларның танып-белү кызыксынуын үстерүгә юнәлдерелгән, аларга мөстәкыйль сайлау мөмкинлеге бирә. Тормыш белән элемтә принцибы тормышка ашырыла.

**Хасанова Гульнур Рафиковна,**
**учитель татарского языка и литературы,**
**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Советлар Союзы Герое Ханжин Павел Семенович исемендәге Тәтеш 1нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе**

# ФЕДЕРАЛЬ ДӘҮЛӘТ БЕЛЕМ БИРҮ СИСТЕМАСЫ КЫСАЛАРЫНДА РУС ТЕЛЛЕ МОХИТ ШАРТЛАРЫНДА ТУГАН ТЕЛНЕ ӨЙРӘНҮ ПЕРЕСПЕКТИВАЛАРЫ

Аннотация. Бүгенге көндә гамәлгә кертелгән яңа буын стандартлары укытучылар һәм тәрбиячеләр алдына яңа бурычлар куйды. Аның гамәлдәгесеннән аермасы - бала шәхесенең игътибар үзәгенә куелуында. Моңа кадәр яшәп килгән гадәти дәресләр, тәрбия чаралары белән генә чикләнеп калмыйча, яңача эш итүне таләп итә ул. Укучыларга белем бирүне генә түгел, ә аларны белем алырга, алган белемнәрен тормышта кулланырга өйрәтүне төп максат итеп куя. Бу исә бездән, укытучылардан, белем бирүнең яңа алымнарын һәм методларын кулланып эш итүне, бүгенге көн таләпләренә җавап биргән дәресләр оештыруны таләп итә.Заманча дәрес нинди булырга тиеш ул? Әлеге мәкаләдә шул сорауга җавап бирелә.

Федераль дәүләт белем бирү стандарты кысаларында туган телне өйрәнү проблемасы бүген бик актуаль. XXI гасыр - фән гасыры, икътисадның һәр тармагында югары инновация һәм технологияләр белән эшләү гасыры. Укучыларны хезмәткә, тормышка әзерләү, аларга сыйфатлы белем бирү - дәүләтнең мәгариф учреждениеләре алдына куйган мөһим бурычы. Заман таләпләре бүгенге көндә туган тел буларак татар телен укыту процессында зур үзгәреш сорый. Безнең алдыбызда бик тә җаваплы һәм әһәмиятле бурыч тора. Беренчедән, телебезне саклап калу бурычы булса, икенчедән, укучыларда телне өйрәнүгә кызыксынуны бетермәү, киресенчә, бу кызыксынуны үстерү бурычы. Бу бездән зур һөнәри осталык, түземлелек һәм заман таләп иткәнчә, югары технологияләрдән, мәгълүмати чаралардан хәбәрдар булуын таләп итә. Бүген уку-укыту процессына яңа технологияләрне кертеп җибәрү- укытучы алдында торган төп таләп, көн тәртибенә куелган беренчел мәсьәлә. Шуңа да без бер урында таптанып тормыйча, шәхес буларак иҗади яктан эш итсәк, нинди дер яңалык эзләсәк, уйлап тапсак кына нинди дер нәтиҗәгә ирешә алабыз. Ә иҗатка төп этәргеч булып укучы тора. Бүгенге дәрестә нинди таләпләр куела соң? Иң беренче чиратта, ул барлык шартлары булган, заманча җиһазландырылган кабинетта узарга тиеш. Икенчедән, укытучы дәреснең максат һәм бурычларын дөрес билгеләргә, эш төрләрен һәм укытучы укучы эшчәнлеген планлаштырырга тиеш. Өченчедән, дәрес проблемалы һәм укучының үсешенә хезмәт итәргә, укучыларны укытучы белән хезмәттәшлеккә этәрергә тиеш. Дүртенчедән, укытучы укучыларны эзләнергә, актив эшләргә, фикерләргә өйрәтергә тиеш. Бу исә укучыларны үзләре нәтиҗә чыгара белергә, иҗадилыкка ирешергә, укучыларның сәламәтлеген саклауга, укучылар белән кире элемтә урнаштырырга, балаларның мөмкинлекләрен истә тотып,нәтиҗәлелеккә ирешүгә шарт тудыра.

Билгеләнгән позиция заманча дәрес оештыруга гомуми якын килүне формалаштырырга мөмкинлек бирә: •

Дәреснең коммуникатив юнәлешен көчәйтү: диалогка, төрле уку һәм тормыш ситуацияләрендә яшьтәшләре һәм өлкәннәр белән аралашуга әзерлек формалаштыру;

• Дәреснең мәгълүмати өлешен арттыру. Дәреслек, хәтта мини-макс принцибына туры китереп төзелгән булса да, дәрестә бердән бер мәгълүмат алу чыганагы булып каралмый;

• Укучыларның уку нәтиҗәләрен бәяләү дә яңа ысуллар кертү;

• Дәреснең технологик өлешен көчәйтү (нәтиҗәле педагогик технологияләр куллану);

• Практик күнекмәләр булдыруга юнәлеш бирү, алардан башка укучыларда предметлы компетенцияләр формалаштырып булмый;

• Балаларның мөстәкыйль эшчәнлеген активлаштыру. “Күп белдерүгә караганда, әз белдереп, эзләнү орлыгын салу һәм эзләү юлларын табарга өйрәтү – мөгаллим бирә ала торган хезмәтләрнең иң зурысы” - дигән мәгърифәтче һәм галим Г.Ибраһимов. Минем фикеремчә, бүгенге көндә заманча технологияләрнең асылын шушы фикер тулысынча тәшкил итә. Чөнки заманча технологияләр кулланып эшләү ул – укучыда өйрәнә торган фәнгә кызыксыну уятуга, аның танып белү активлыгын үстерүгә, укучының иҗади мөмкинлекләрен камилләштереп, белемнәрен тирәнәйтүгә зур ярдәм итә. Компьютер - укучы белән белемнәр системасы арасында арадашчы, белем алу чарасы.Аны бары тик урынлы һәм нәтиҗәле кулланырга гына кирәк. Хәзер һәрберебездә ноутбуклар бар.Укучыларның белемнәрен тикшергәндә, өстәмә мәгълүмат биргәндә бу ноутбуклар бик уңай. Дәресләрнең нәтиҗәлелеген арттыруда компьютер яки мәгълүмати технологияләр аерым урын алып тора. Алар белемнәрне камилләштерүдә, ныгытуда , эзләнүләр, тәрбия һәм тикшерүләр алып баруда, үзгәрешләр кертүдә ярдәм итәләр. Компьютер яки мәгълүмати технологияләрне файдалану дәреснең нәтиҗәлелеген күтәрә, укучыларның кызыксынучанлыгын арттыра, өлгереш күрсәткечен һәм уку сыйфатын яхшырта.

Заманча технологияләрне укыту-тәрбия эшендә гамәлгә ашыру, укытучыдан фәнни-методик яктан әзерлек белән беррәттән, укытуда гадәти булмаган, оригиналь, кызыклы эш алымнары табарга тырышуы да тора.

Мин “Дәресләрдә укучыларның уен технологиясе аша сөйләм телләрен устерү” дигән методик тема өстендә эш алып барам. Шуңа күрә укучыларның иҗат мөмкинлекләрен ачыклау өчен, дәресләрдә тиешле шартлар тудырырга тырышам: дәрес-әңгәмә,дәрес-уен , дәрес-сәяхәт, дәрес- проект, дәрес-семинар, дәрес- конференция дәресләре уздырам. Балалар андый дәресләрдә бер-берсе һәм укытучы белән фикерләшә, аралаша. Бигрәк тә, проект эшләрен укучылар бик теләп эшлиләр. Узган уку елында бик күп проект эшләре белән төрле конкурсларда, фәнни-гамәли конференцияләрдә катнаштык. Үзләре кызыксынып, 10 нчы сыйныф укучылары Галиякберов Ранис һәм Чубукова Татьяна “Нәрсә ул бәхет?!” исем астындагы проект эше белән үзебезнең мәктәптә “Камай укулары “фәнни-гамәли конференциясендә чыгыш ясап, 1 урынга лаек булдылар. Балаларыбыз белән уңышлы гына төрле районара һәм республикакүләм конкурсларында,олимпиадаларда,төрле фәнни конфереции яләрдә катнашып югары дәрәҗәдәге урыннар яулыйлар. Алда әйтелгәннәрдән нәтиҗә ясап, шуны әйтергә була: педагогика фәнендә укыту-тәрбия процессы сыйфатын үстерергә булышлык итүче технологияләр шактый. Укытучының бурычы - яңалыклар

агымында югалып калмыйча, дөрес юнәлеш алу, укытуның һәр этабы өчен уку материалын аңлатуның иң уңышлы вариантын табу. Шул ук вакытта аларның бер-берсе белән ярашырга тиешлеген дә онытмау зарур. Туган тел дәресләрендә мәгълүмати технологияләрне куллануның өстенлеге бәхәссез. Барыннан да элек алар – шәхескә юнәлтелгән ныклы һәм вариатив. Төрле технологияләр, компьютер, мультмедиа технологияләре күрсәтмәлелекне, контрольлекне тәэмин итеп һәм күп мәгълүмат биреп, укытуның сыйфатын күтәрергә ярдәм итә, этәргеч бирә. Кеше бу дөньяда нинди генә биеклекләргә ирешсә дә, аның уңышлары башында укытучы тора.Тик шулай да үз белемеңне күтәрү өстендә туктаусыз эшләү генә тиешле нәтиҗәләр бирә. Алда әйтелгәннәргә нәтиҗә буларак атаклы педагог К.Д. Ушинский сүзләрен китерергә мөмкин:

“Укытучы һәрдаим укыганда гына укытучы булып кала”-дигән. Әйе, тырышмыйча гына укучыларга үз фәнеңне яраттырып булмый. Үзалдыңа билгеле бер максат –бурычлар куеп, шуларны тормышка ашырганда гына моңа ирешергә була.

Хөрмәтле кунакларыбыз,коллегалар! Сезгә иҗади уңышлар, көтелмәгән шатлыклы мизгелләр, гаиләгезгә иминлек, бәхет алып килсен. Бергә һәм бердәм булып эшләргә язсын! Шуның белән чыгышым тәмам Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт.

Кулланылган әдәбият:

1.Асадуллин А.Ш. Дидактический материал для русскоязычных учащихся. Казан«Гомуми белем бирү федераль дәүләт стандартлары концепциясе» - «Концепция федеральных государственных образовательных стандартов общего образования»;

2..«Государственая программа Республики Татарстан «Сохранение, изучение и развитие языков РТ и других народов в Республике Татарстан на 2014-2020 годы» - «2014-2020 нче елларда ТР сы дәүләт телләрен һәм ТРның башка халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү» ТРсы дәүләт программасы (ТР Министрлар Кабинетының 2013 нче елның 25 нче октябреннән 794 нче карары)

3.Журнал "Магариф",2002 г.,№6,№8

4.Закон Республики Татарстан «Об образовании» - «Мәгариф турында» гы Татарстан Республикасы законы (№ 68, 2013 нче елның 22 нче июле); «Россия Федерациясе халыклары телләре турында» «О языках народов Российской Федерации»

5.Мозаффарова М.Г. "Әдәбият" предметын укыту үзенчәлекләре. Татар әдәбияты буенча төп, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә куя торган педагогик хезмәткәрләр өчен тәкъдимнәр. Казан. ТРМҮИ. 2014

6.."Обучение татарской устной речи" Лингводидактические основы. Издательство "Магариф",130стр.

7.«О государственных языках Республики Татарстан и других языках в Республике Татарстан», «ТР дәүләт телләре һәм ТРсындагы башка телләр турында»гы Татарстан Республикасы законы;

8.«Россия Федерациясе мәгарифе турында»гы федераль закон - ФЗ «Об образовании в Российской Федерации» ( 2012 нче елның 29 нчы декабрендә Россия Федерациясе Президенты тарафыннан имзаланган 273 нче ФЗ; 2013 нче елның 1нче сентябреннән гамәлдә).

**Хафизова Ф.З.,**
**татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы**
**Әгерҗе шәһәре муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе**
**4 нче номерлы гомуми урта белем бирү мәктәбе**

# УКУЧЫЛАРНЫҢ ИҖАДИ МӨМКИНЛЕКЛӘРЕН АЧУ ҺӘМ ҮСТЕРҮДӘ ПРОЕКТ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ РОЛЕ

Һәр балада иҗади сәләт яшеренеп ята. Аның үсешенә күтөрле факторлар йогынты ясый. Нәселдәнлек, китап уку, әйләнә-тирә мохит, дуслар-фикердәшләр булу. Иң мөһиме – баладагы иҗади потенциалны күрүче бер кеше булу. Әгәр дә иҗатка сәләте булган, күңелендә иҗат очкыннары янып торган укучыга тиешле юнәлеш бирсәң, нәтиҗәсе булачак. Рус мәктәпләрендә дә бик сәләтле укучылар – милләтебезнең асыл балалары белем ала. Көне буе рус мохитендә яшәп, атнага 2-3 сәгать бирелгән татар теле дәресләрендә генә бала белән иҗат эше алып барып булмый. Иҗат итү теләге булган, туган телен өйрәнергә, киләчәген татар теле белән бәйләргә теләүче; туган теленең матурлыгын тоючы, аны күңеленә сеңдереп баручы укучылар булу яңа проектлар уйлап табарга этәрә.

Бу проект укучыларны халкыбызның рухи-әхлакый кануннары белән таныштыра, югары сөйләм культурасы формалаштыра, иҗади сәләтләрен үстерә, мөстәкыйль уйлау һәм эшләү омтылышын канәгатьләндерә, үзләренең сәләтләрен, көчләрен максималь кулланырга, татар әдәби сүзе үсешенә өлеш кертергә, эш нәтиҗәләрен башкалар алдында күрсәтергә ярдәм итә.

**Проектның кирәклеген нигезләү**

Иҗат эше - беркайчан искерми торган бер юнәлеш. Һәр заман үз иҗатчыларын, үз геройларын иҗат төрләрен һәм формаларын үзгәртеп бирә тора. Борынгы кульязма әдәбияттан алып бүгенге электрон китапларга кадәр озын юл үткән иҗат һәрчак эзләнүдә. Милли басма сүз калын-калын җыентыклардамы, әллә кечкенә китапчыклардамы барыбер бер вазифаны башкара: туган тел сагында тора. Бу проект рус телендә белем бирүче мәктәптә иҗади юнәлешле балаларны бергә туплау ягыннан да актуаль. Иҗади эшләүче, үзем дә иҗат итүче педагог буларак, белгәннәремне укучыларыма тапшыру, күңелләрендәге иҗат утын сүндермичә, яңа темалар биреп, яңа конкурсларга әзерләп, төрле басмаларда иҗатларын яктыртуны актуаль һәм нәтиҗәле эш, дип саныйм.

**Проектның максаты һәм бурычлары**

Иҗади проектның макcты - “Биш йолдыз” исемле журнал бастыру һәм район күләмендә үткәрелүче “Көмеш каләм” яшь иҗатчылар фестивалендә катнашучы укучыларга тәкъдир итү.

Бурычлар :

1. Иҗат эше белән актив шөгыльләнүче биш укучының 1-7 сыйныф аралыгында иҗат ителгән бөтен әсәрләрен аерым папкаларга туплау.
2. Быелгы уку елында яңа темалар буенча иҗат итү.
3. “Биш йолдыз” эмблемасын уйлап табу.
4. Җыелган материалларны төркемнәргә бүлү, рубрикаларга исем уйлау.

5. Журналның караламасын ясау.
6. Журналның макетын булдыру.
7. Журнал бастыруның матди ягын хәл итү.
8. Журналны бастыру һәм иҗади аудиториягә тарату.

**Проектның төп эчтәлеге**

“Биш йолдыз” проекты буш урында гына тумады. Биш кыз (Алсу, Алсу, Азалия, Адэлина, Алинә) 1нче сыйныфтан башлап төрле конкурсларда, конференцияләрдә, иҗади проектларда катнашып, “Яңарыш”, “Әгерҗе хәбәрләре”, “Көмеш кыңгырау” газеталарында, “Сабантуй” журналында язмалары басылып, актив иҗади тормыш белән яшәделәр. Исемне дә укучылар белән бергәләп уйлап таптык. “Биш йолдыз” дигән журнал бастырып, туган телдә иҗат ителгән шигырь, хикәя, очерк, мәсәл, мәзәк, башваткычларны башкаларга да күрсәтүне кирәк санадык.

Эш барышында критик фикерләү, креатив эшчәнлек, аралаша белү, үзара хезмәттәшлек компетенцияләре үстерелә. Проект өстендә эшләү - дәрестән тыш эшчәнлек. Шуңа күрә укучыда кызыксыну һәм теләк булу гына нәтиҗәгә китерә ала.

**Кирәкле ресурслар**

1. Проектны тормышка ашыручы матди ресурс – грант акчасы.
2. Укучылар иҗаты яктыртылган төрле басмалар.
3. Төркем эшчәнлеге өчен кабинет.
4. Компьтер кабинеты белән бәйләнеш.
5. Журнал макетын төзү буенча “Яңарыш” газетасы дизайнеры белән элемтә.
6. Район күләмендә үткәрелүче “Көмеш каләм” фестивале.

**Максатчан аудитория**

Проектта катнашучылар – 4 нче номерлы гомуми урта белем бирү мәктәбенең 7 нче сыйныфы татар төркемендә белем алучы 5 укучы. Аларга 13-14 яшь.

Партнерлар - 4 нче номерлы гомуми урта белем бирү мәктәбенең татар теле укытучылары, информатика укытучысы. “Әгерҗе хәбәрләре” район газетасы. Удмуртиядә чыгучы “Яңарыш” газетасы.

**Проектны гамәлгә кертү этаплары**

1 этап - әзерлек этабы – 2020 нче елның ноябре

-проектны эшләү;

- укучылар белән проект турында фикерләшү;
- проектның иҗади төркемен төзү;

2 этап – проектны тормышка ашыру – 2020 нче елның декабре - 2021 нче елның апреле

- язмаларны җыю, аерым папкаларга туплау;
- түгәрәк өстәлләр үткәрү, журнал эчтәлеге буенча фикер алышу;
- иҗади эшләрне тематикалап бүлү;
- журнал өчен рубрика исемнәре уйлау;
- журналның компьютер вариантын – макетын төзү;
- журналны бастыру;
- киң аудиториягә тәкъдир итү.

3этап – йомгаклау этабы – 2020 нче елның июль ае

-проект нәтиҗәләре буенча отчет бирү.

**Проектны тормышка ашыру планы**

| № | Проектның этабы | Проект чаралары | Үтәү вакыты | Көтелгән нәтиҗәләр |
|---|---|---|---|---|
| 1. | 1 этап – әзерлек | Проектны эшләү. | 16 -26.11.2020 | Проект язмасы |
| | | Укучылар белән проект буенча фикерләшү. | 20-30.11.2020 | Ачыкланган проблемалар |
| | | Проектның иҗади төркемен төзү. | 30.11.2020 | Иҗат итүче укучыларның төркеме |
| 2. | 2 - этап – проектны тормышка ашыру | Проектны тормышка ашыру планын төзү | 04.12.2020 | Проектның тормышка ашыру планы |
| | | Язмаларны җыю, аерым папкаларга туплау. | Декабрь,2020 | Журнал өчен материал туплану |
| | | Түгәрәк өстәл үткәрү, журнал эчтәлеге буенча фикер алышу | Гыйнвар, 2021 | Укучыларның яңа фикерләре, яңа идеяләре |
| | | Түгәрәк өстәл үткәрү, журнал эчтәлеге буенча фикер алышу. | Февраль, 2021 | Осталык арту, иҗади көч арту |
| | | Иҗади эшләрне тематикалап бүлү. | Март, 2021 | Материалларны төркемләү, камилләштерү |
| | | Журнал өчен рубрика исемнәре уйлау. | Март, 2021 | Яңа рубрикалар, заманча яңгыраш |
| | | Журналның компьютер вариантын – макетын төзү. | Март, 2021 | Журнал макеты |
| | | Журналны бастыру. | Апрель, 2021 | “Биш йолдыз” журналы нөсхәсе |
| | | Киң аудиториягә тәкъдир итү. | Апрель, 2021 | “Көмеш каләм” фестивалендә чыгыш-презентация |
| 3 | 3 этап - йомгаклау | Проект нәтиҗәләре буенча отчет бирү. | Июль, 2021 | Проект җитәкчесенең отчеты |

**Проектның киләчәк үсеш перспективалары**

1. Проектны эшләү барышында татар телен өйрәтүгә иҗади якын килү күзәтелә, телгә өйрәнүгә уңай мотивация барлыкка килә.

2. Проектта катнашучыларның ата-аналарында иҗатка карата уңай караш туа, укучыларда белем базасы формалаша.

3. Проектның уңай һәм тисәре яклары нәтиҗәләре буенча түгәрәк өстәлләр, чыгышлар планлаштырыла.

4. Әзер продукт – журнал чыгару турында вакытлы матбугат чараларында яктыртыла.

5. Проект кысаларында иҗатка сәләтле укучылар базасы булдырыла, регионара “Көмеш каләм”, республика күләмендәге “Алтын каләм” яшь иҗатчылар фестивальләренә катнашучылар әзерләнә.

**Шамсутдинова Р.А., учитель родного (тат.) языка и литературы**
**МБОУ “Бакрчинская СОШ” ТМР РТ**

В данной статье я поделилась личным опытом по формированию функциональной грамотности на уроках родного (тат.) языка и литературы, используя интернет ресурсы на татарском языке, а именно блогер-татар и ютуб каналов.

Туган тел һәм әдәбият дәресләрендә функциональ белемлелекне формалаштыру/Формирование функциональной грамотности обучающихся на уроках родного языка и литературы

Функциональ белемлелек ул- кешенең тышкы мохит белән мөнәсәбәтләргә керү һәм максималь тиз җайлашу һәм анда эшләү сәләте. Ул шәхеснең уку, аңлау, гади кыска текстлар төзү һәм гади арифметик гамәлләр кылу сәләтеннән аермалы буларак, социаль мөнәсәбәтләр системасында шәхеснең нормаль эшләвен тәэмин итә торган атомар белем, осталык һәм күнекмәләр дәрәҗәсе; ул конкрет мәдәни мохиттә шәхеснең тормыш-көнкүрешен тормышка ашыру өчен иң кирәкле белемлелек булып санала.

Функциональ белемлелек, элементар грамоталылыктан аермалы буларак, шәхеснең ситуатив характеристикасы булып тора. Ул үзен конкрет статистик ситуациядә, яшәү рәвеше яки һөнәри эшчәнлек төре үзгәргәндә ачыклый.

Хәзерге авыр вәзгыятьтә татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә укучыларның функциональ белемлелеген арттыру иң зур бурычларның берсе булып тора, чөнки беребезгә дә сер түгел: татар теленең функцияләре кими, ул тормышның барлык өлкәләрендә тигез дәрәҗәдә кулланыла алмый. Әгәр без яшь буынның күбесенчә рус телендә сөйләшүенә, туган телебезнең “әби-бабай теленә” генә әйләнүенә битараф булсак, милләт буларак яшәүдән туктаячакбыз. Биредә туган тел укытучылары алдында бик авыр мәсьәлә тора: ничек итеп укучыларда ана теленә мәхәббәт уятырга, нинди юллар, ысуллар белән аларны туган телебезне өйрәнергә чакырырга? Үз эш тәҗрибәмнән чыгып, бу ысулларның берничәсенә тукталып үтәргә рөхсәт итегез.

2012 нче елдан Бакырчы урта гомуми белем бирү мәктәбе рус телендә белем бирүче мәктәпкә әйләнде, чөнки күрше авылдан чуваш балалары безгә килеп кушылды. Барлык предметлар да рус телендә укытыла, укучылар атнага өч дәрес туган тел һәм әдәбият дәресләрендә генә ана телендә сөйләшәләр. Моңа өстәп, интернет, төрле мессенджерларда аралашу, телевидение, балалар яратып карый торган ютуб каналы, төрле модалы пабликлар- барысы да рус телендә. Милли үзаңнары үсмәгән ата-аналар

моның өчен бик ундырышлы җирлек булдылар. Менә шундый авыр шартларда туган тел укытучылары балаларны ана телләрен өйрәнүгә җәлеп итәргә тырышалар, өендә бер әдәби китап укып карамаган ата-аналарның күңел кылларына чиртергә телиләр.

Бүгенге көн укучыларының интернет корбаннары булуын исәпкә алып, татар телле пабликларны, блогерларны барларга керештем. Алар минем берничә таләпкә җавап бирергә тиеш иде: туган телдә алып барылсын, аларның хуҗалары билгеле шәхесләр булсын, контентлары яшь аудитория булсын, иң мөһиме, аларда кызыклы темалар күтәрелсен. Әлбәттә, мин инстаграмда аккаунт булдырдым һәм эшкә керештем.

Башта мин укучылар арасында сораштыру үткәрдем: татарча алып барыла торган инстаграм аккаунтына язылучы бармы? **Кызык-мызык, Татар малай**га язылучылар бар булып чыкты. Татар малай- Ринат Галиәхмәтовның шәһәр малае булганлыгы, татар телен бик әйбәт белүе, беренче татар блогеры булуы, кызыклы гына сюжетлар төшерүе әйтелеп, иплэп кенә, татар телен белү бу егеткә танылырга, үз өстендә эшләргә, финанс хәлен яхшыртырга мөмкинлек биргәнлеге нәтиҗә ителеп әйтелде.

Хәзер инде мин татар телле аккаунтларны тәкъдим итү эшен башлап җибәрә алам, дигән фикергә килдем. Һич курыкмыйча, түбәндәге блогерларны укучыларга тәкъдим иттем:

**Раил Гатауллин rail_belem.ru**
**Айсылу Лерон iceluleron**
**МинемЯраткanТуганТелем minemyaratkantatartelem**
**Лейла Лерон pepemeygan**

Бу аккаунтларда укучылар милли, шәхси яктан үсеш алачаклар, кызыклы фактлар, тормыш-яшәеш буенча төпле киңәшләр ала алачаклар.

Ләкин карап бару гына аз, укучылар белән үз аккаунтларында да татарча язмалар урнаштырырга сөйләштек. Моның өчен татарча шрифт кирәк иде, әлбәттә. Татарның газиз хәрефләре дә үз урыннарында төгәл һәм дөрес утыралар хәзер.

Әле бит укучыларның яраткан ютуб каналлары да бар. Язылу гына җитми, алар аны кызыксынып карап барсын өчен, җәлеп итәрлек материаллары да булырга тиеш. Көтелгәнчә, татар телле ютуб каналга беркем дә язылмаган булып чыкты. Монда инде бер дә курыкмыйча, **Taplink.cc|tatartell** каналын тәкъдим иттем. Креатив шәһәр яшьләре төрле темаларга сюжетлар тәкъдим итәләр, татарча сөйләшәләр, бәхәсле мәсьәләләр күтәрәләр. Дөрес, алар да русчалы-татачалы сөйләшергә мөмкиннәр, монысын танырга кирәк.

Хәзерге балаларның сөйләм теле ярлы булуы, монологик төрнең дәрестә бик авырлык белән баруы, русча калькалар белән сөйләшүләре сер түгел. Сөйләм хаталарыннан ничек котылырга, укучыларга үзләре ясый торган сөйләм, грамматик хаталарны ничек эффектлы итеп күрсәтергә, алардан котылу юлларын ничек җиңел итеп аңлатырга- бу да көн кадагында торучы мәсьәләләрнең берсе. Укучылар кулындагы коралны тагын кулланып карарга булдым. Өй эше итеп, **матбугат.ру** сайтына язылуларын сорадым (бу 9-11 сыйныфлар) һәм сөйләм хаталы элмә такталар фотоларын сайтта эзләүләрен үтендем. Дәрестә без бу хаталарны төзәтү өстендә эшлибез, стилистика, синтаксис бүлекләрен үткәндә кулланабыз, үзләреннән дә, хаталы язуларны күргәндә, төшерүләрен сорадым.

Хөрмәтле коллегалар, кечкенә генә чыгышымда мин туган телебезнең функцияләрен арттыру юлында татар телле интернет ресурсларын куллануны күрсәтеп

үттем. Батып баручыны кешене коткару өчен, ул кешенең батарга теләмәве кирәк. Гамәлгә ярашлы, әдәп-әхлак кысаларыннан чыкмаган, фәнни яктан расланган теләсә нинди юлны без кулланырга, туган телебезнең юкка чыкмавына сәбәпче булырга тиешбез. Игътибарыгыз өчен рәхмәт.

*Шәйхетдинова Румия Рәхимҗан кызы,*
*«Ханжин Павел Семенович исемендәге*
*Тәтеш 1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе»*
*муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең*
*югары квалификация категорияле*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

## ФУНКЦИОНАЛЬ УКУ ГРАМОТАЛЫЛЫГЫН ФОРМАЛАШТЫРУ АЛЫМНАРЫ

*Аннотация*

Мәкаләдә уку грамоталылыгы формалаштыруның актуальлеге күрсәтелә, төрле эш алымнарын, мәгълүмат чыганакларын, уку күнекмәләре белән бәйле биремнәр куллану аша, уку грамоталылыгына ирешү юллары ачыла.

Төп төшенчәләр: функциональ грамоталылык ,уку грамоталылыгы**.**

Функциональ грамоталылык –кешенең тышкы мохит белән бәйләнешкә керә белүе һәм шунда, тиз арада җайлашып,төрле функцияләр башкаруы,эшли алу сәләте .

Федераль дәүләт белем бирү стандартында мәгарифнең төп максаты **“баланың шәхси үсеше**”дип билгеләнгән. Универсаль уку гамәлләрен формалаштыру -бу мәсьәләне уңышлы үтәүнең бер шарты. Универсаль уку гамәлләре арасында **уку компетентлыгы** үзәк урынны алып тора. Хәзерге вакытта уку грамоталылыгы иң мөһим компетентлыкларның берсе.Ул заманча социумда яшәргә әзерлекне күрсәтә.

**Уку грамоталылыгы**- кешенең язма текстларны аңлап укуы, куллана белүе, аның буенча фикерләү сәләте; үз максатларыңа ирешү, белемнәрне , мөмкинлекләрне киңәйтү, социаль тормышта катнашу өчен уку.Ни өчен уку грамоталылыгы белем бирү системасының уңышлы булуында төп күрсәткеч булып санала? Беренчедән,текстлардан алынган мәгълүматны аңлый һәм куллана белү шәхси язмышларга да, илнең иминлегенә дә сизелерлек йогынты ясый. Икенчедән,уку грамоталылыгы югары дәрәҗәдә булган унбиш яшьлек укучы мәктәпне уңышлы тәмамлап, белем алуны дәвам итәчәк.Өченчедән, уку грамоталылыгы дәрәҗәсе , башка уку казанышларына караганда, илдәге икътисади үсешне яхшырак фаразлый.

PISA Халыкара тикшеренүләре Россия укучыларының тексттан мәгълүматны табып алу, интеграцияләү һәм интерпретацияләү, текстны аңлый һәм бәяли белү дәрәҗәсендә үз яшьтәшләреннән артта калуларын ачыклаган.

Укучыларның уку грамоталылыгын формалаштыру максатыннан,дәресләрне һәм дәрестән тыш эшчәнлекне инновацион технологияләргә нигезләнеп оештырам.Бу

максатны үз эченә алган инновацион технологияләрнең берсе - ул тәнкыйди фикерләү технологиясе.

Тәнкыйди фикерләү технологиясең ысуллары күп төрле.Текстны укыганчы (чакыру стадиясендә “Ми һөҗүме”,“Идеяләр кәрзине”,Тәлгәш” (кластер), ”Фаразлар агачы”алымнарын кулланам,ә текстны укыган вакытта (аңлау стадиясендә)калын һәм нечкә сораулар ( гади-катлаулы), ”Инсерт”, “Тукталышлар ясап уку”, “Блум шакмагы”, “Сюжет таблица”сы алымнары отышлы. Рефлексия этабында “Кластер”, ”Синквейн”, “Икеяклы көндәлек”, “Алты эшләпә”, “Балык кылчыгы”алымнары нәтиҗәле дип саныйм.

Шуны билгеләп үтәсем килә, уку грамоталылыгын үстерү барлык дәресләрдә һәм дәрестән тыш вакытта, бала китап яки теләсә нинди мәгълүмат чыганагы белән очрашканда да дәвам итә. *Бирелгән мәгълүмат чыганакларын ике төркемгә бүлегез. Нәрсәгә нигезләнеп бүлеп була?Хикәя,график,повесть, афиша, очерк, чек, диаграмма, инструкция, роман.*

| **Тоташ текстлар** | **Тоташ булмаган текстлар** |
|---|---|
| хикәя | афиша |
| повесть | чек |
| очерк | диаграмма |
| роман | инструкция, |
|  | график |

Мәгълүмат чыганаклары булган текстлар ике төркемгә бүленә:тоташ текстлар,тоташ булмаган текстлар. Хәзерге вакытта балалар тоташ булмаган текстлар белән көндәлек тормышта ешрак та очраша.

Тоташ булмаган текстларны укый беләләрме ? (турыдан-туры бирелгән мәгълүматны һәм күзгә күренмәгән мәгълүматны таба алып, аны аңлата алалармы?) Менә иң гади мисал: «Сан төркемчәләре» дип аталган таблицаны тутырырга. Таблица баганаларының исемнәре бирелгән һәм бу баганаларга бүләргә кирәк булган сүзләр: *биш,алтынчы,җидәү,бер,икенче,өчәү,дүрт,*
*сигезенче,унбиш,унау,микъдар,тәртип,җыю*

| **Саннар** | **Сан төркемчәләре** |
|---|---|

Ничек эшләргә кирәк? Башта биремнең формулировкасын укырга кирәк. Сүз уңаенда, күп кенә укучылар биремнәрне укый белми, шуңа күрә нәтиҗә дә булмый.

1. Таблицаның исемен укыйбыз: «Сан төркемчәләре».

Нинди мәгълүмат ачык күренә?(Санның төркемчәләре бар). “Юллар арасында " нәрсә укыйбыз? Бу төркемчәләр берничә (төркемчәләре-күплек сан формасы кулланылды). Укучыда нинди сорау туа? Бу төркемчәләрничә һәм нинди алар?

2. Бу сорауга җавап эзлибез: таблицаның багана исемнәрен укыйбыз: саннар, сан төркемчәләре?

Алар нинди өстәмә мәгълүмат хәбәр итәләр? Саннарны һәм аларның төркемчәләрен күрсәтергә кирәк. Биредә турыдан туры бирелмәгән мәгълүмат бар: ике багана күрсәтелгән, димәк, барлык сүзләрне ике төркемгә бүләргә кирәк.

3. Бу баганаларга бүләргә кирәк булган сүзләр: биш,алтынчы,җидәү,бер,икенче,өчәү, дүрт,сигезенче,унбиш,унау,микъдар,тәртип,җыю.

Биредә барлык саннар һәм сан төркемчәләре. Менә сорауга җавап (төркемчәләр ничә һәм нинди алар?) подтекстта: саннарны төркемнәргә аерырга кирәк, ә исемлектә өч төркемнең исеме бирелгән (микъдар,тәртип, җыю), ә баганалар ике, димәк таблицада алты ячейка булачак. Биремдә бу хакта турыдан-туры әйтелмәгән, әмма без бу мәгълүматны «юллар арасында»таптык.

Эш нәтиҗәсе-таблица.

| **Саннар** | **Сан төркемчәләре** |
|---|---|
| **Бер , дүрт, биш, унбиш** | **микъдар** |
| **икенче, алтынчы, сигезенче** | **тәртип** |
| **өчәү, җидәү, унау** | **җыю** |

Барыннан да элек балалар биремне укырга, турыдан-туры нәрсә турында сөйләнгәнне, ә нәрсә турында аңлап булганны ;тоташ булмаган текстларны мөстәкыйль төзи белергә , мәгълүматны бер формадан икенчесенә күчерергә, телдән бәйләнешле сөйләм төзергә өйрәнә.Укучыларның кызыксынуы арта һәм уку нәтиҗәләре дә яхшыра.

Укылган текст эчтәлеге нигезендә сораулар (биремнәр) системасын формалаштыру;

алынган мәгълүматны яңа ситуациядә куллану;

яңа һәм элегрәк алынган мәгълүматны чагыштыру; билгеле бер темага, шул исәптән тоташ булмаган текстлардан алынган мәгълүматны кулланып мини-проектны (проект) ясау.

Уку грамоталылыгы формалашкан укучы түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиеш.

**Беренче төркем уку күнекмәләре белән бәйле биремнәр**

**1.Ачыктан-ачык рәвештә бирелгән мәгълүмат эзләү**:

-конкрет мәгълүмат табу;

-сүзләрнең һәм фразаларның мәгънәсен билгеләү ;

-тема яки төп идеяне билгеләү, әгәр алар текстта ачык рәвештә бирелсә;

-хикәядә сөйләнгән вакыйганың вакытын һәм урынын билгеләү;

-текстта булган фактлар нигезендә нәтиҗәләр ясау:

-вакыйгалар арасында бәйләнешләр урнаштыру;

-тексттагы гомумиләштерүне аңларга (билгеләргә);

-аргументлар сериясенә нигезләнеп, гомуми мәгънәне чыгару.

**Икенче төркем уку күнекмәләре белән бәйле биремнәр**

**2.Мәгълүматны интерпретацияләү һәм гомумиләштерү:**

-гомуми идеяне , текст темасын белү;

-геройлар арасындагы мөнәсәбәтләрне тасвирлау;

-тексттан алынган мәгълүматны чагыштыру һәм каршы кую;

-текстның эмоциональ һәм гомуми тонын аңлау;

-тексттагы мәгълүматны гамәлдә куллану.

**Өченче төркем уку күнекмәләре белән бәйле биремнәр**

**3. Текстның эчтәлеген, телен һәм структурасын бәяләү:**

-тасвирланган вакыйгаларның дөреслеген бәяләү;

-авторның, көтелмәгән нәтиҗә булдыру өчен , нинди чаралардан файдалануын тасвирлау;

-текстта бирелгән мәгълүматның тулылыгын яки ачыклыгын бәяләү;

-авторның текстның төп темасына мөнәсәбәтен билгеләү.

Уку грамоталылыгын формалаштыру буенча эшнең нәтиҗәлелеге, барыннан да элек, педагогка бәйле, уку эшчәнлеген оештыручы буларак, әлеге процессның кызыклы катнашучысы булу-аның бурычы. Шул вакытта гына ул әйтә ала: «Минем укучыларым яңа мәгълүматны миннән генә белмәячәк, алар бу яңалыкны үзләре ачачак» (Иоганн Генрих Песталоцци)

**Кулланылган әдәбият**


1. Анисимова Л.М. Формирование читательской компетентности., 2013г.
2. Асмолов А.Г. Формирование универсальных учебных действий в основной школе: от действия к мысли. Система заданий для учителя. – М.: Просвещение, 2010,-159 с.
3. Г.А. Цукерман, Г.С.Ковалева, М.И. Кузнецова «Хорошо ли читают российские школьники?»



**Шәрипова Роза Александровна, МББУ “Советлар Союзы Герое ГГ.. Гарифуллин исемендәге Яңгул гомуми урта белем мәктәбе”нең татар теле һәм әдәбияты укытучысы**


## ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ ПРОЕКТ ТЕХНОЛОГИЯСЕ


Аннотация

Татар теле һәм әдәбиятын укытуда кулланылучы инновацион технологияләр арасында проектлар методы әһәмиятле урын алып тора. Бу метод белән эшләгәндә, укучылар актив рәвештә уйлау, фикерләү эшчәнлегенә тартылалар. Укыту процессында яңа педагогик технологияләрне куллану - яңа метод һәм алымнарны үстерергә, яңача эшләргә ярдәм итә. Без, татар теле һәм әдәбияты укытучылары, дәрестә өйрәнгән теманы җиңел юл белән үзләштерә торган, белем сыйфатын күтәрүгә файдалы булган проектлар технологиясен һәм эзләнү-тикшеренү методын куллану уңай күренеш дип саныйм.


*«Белемнең сыйфатын тамырдан үзгәртә торган*
*механизмнар булдырырга кирәк. Моның өчен*
*заманча белем технологияләрен актив куллану зарур»*

**В.В.Путин**

Минем үземнең чыгышымны күренекле мәгърифәтче һәм галим Г.Ибраһимов сүзләре белән башлыйсым килә: “Күп белдерүгә караганда, әз белдереп, эзләнү орлыгын салу һәм эзләү юлларын табарга өйрәтү – мөгаллим бирә ала торган хезмәтләрнең иң зурысы”.Бүгенге көндә дә заманча технологияләрнең асылын Г.Ибраһимовның шушы

фикере тулысынча тәшкил итә, чөнки заманча технологияләр кулланып эшләгәндә генә – укучыда өйрәнә торган фәнгә кызыксыну уятып, аның танып белү активлыгын үстереп була.

Ә менә балаларда үз фәнеңә ничек кызыксыну уятырга соң? Миңа үземнең эшемдә инновацион технологияләр ярдәм итә. Бүген шуларның берсе – проект технологиясенә тукталырбыз.

**Проект эшчәнлегенең актуальлеге**

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә проект эшчәнлеген куллану отышлы. Проект эшчәнлеге укучы шәхесенең белем алуга иҗади якын килүенә юнәлтелгән. Бу метод белән эшләгәндә, укучылар актив рәвештә уйлау, фикерләү эшчәнлегенә тартылалар. Тиешле нәтиҗәгә ирешү өчен, эш барышында әдәби китаплардан, сүзлекләрдән, интернет аша күп мәгълүмат тупларга, иҗади фикер йөртергә кирәк. Проект эшен башкарганда укучылар өстәмә чыганаклар эзләргә, табылган мәгълүматларны кулланырга өйрәнәләр, аралашу күнекмәләрен үстерәләр, фәнни-тикшеренү күнекмәләрен камилләштерәләр, төркемнәрдә эшләргә өйрәнәләр, аларда җаваплылык хисе, үз-үзенә ышаныч формалаша. Гомумән, проект методы - баланың интеллектын, иҗади сәләтен, логик фикерләвен үстерүдә нәтиҗәле алымнарның берсе булып тора дип уйлыйм мин.

*Проект эшчәнлегенең нигезе* - эзләнү-тикшеренү эше. Эшнең уңышлы килеп чыгуы аның дөрес планлаштырылуына бәйле. Монда укытучы, укучы һәм ата-ана хезмәттәшлеге бик әһәмиятле.

Проектлар методы бер яки берничә фән эчтәлегенә нигезләнергә мөмкин. Проектлау укучыларның мөстәкыйль эше булса да укытучы җитәкчелегеннән башка уңышлы була алмый .

Мин сезгә 5 нче сыйныф укучылары белән эшләгән **«Гомерендә - халкы язмышы, җырларында – халкы моңнары»** исемле проект паспортын тәкъдим итәсем килә.

**Проектның максаты:** Балаларны Г.Тукай иҗади эшчәнлеге белән кызыксындыру өлкәсендә эффективлыкны күтәрү.

**Проектның бурычлары:**

- Габдулла Тукайның иҗатының музыка белән тыгыз бәйләнештә булуын ачыклау.
- Габдулла Тукайның әсәрләренә мәхәббәт һәм сакчыл караш тәрбияләү.
- Габдулла Тукай иҗаты аша балаларда гомумкешелек, намуслык, тугрылык, кайгыртучанлык сыйфатларын тәрбияләү.
- Иҗади сүздән ләззәт табып, шуны үзенең сөйләмендә куллана белену тәрбияләү (табышмаклар, әйтемнәр, халык аваз иҗаты).
- Габдулла Тукайның шигырьләрендә һәм әкиятләрендәге махсус сөйләм телен сиземләү һәм аңлауны тәрбияләү.

**Проектны тормышка ашыру этаплары**

*Беренче этап.*

Укучыны кызыксындыру максатыннан эшләнелгән буклетлар, укытучының старт презентациясе, проект эшенең барышы турындагы аңлатма - презентация, укытучы визиткасында кулланылган ресурслар, мәгълүмат алу чыганаклары, методик күрсәтмәләр бирелде.Үрнәк максатында укучыларның эшләре, аларны бәяләү

критерийлары бирелде, аларны карау, фикер алышу оештырылды. Башта, укучыларның белемнәрен тикшерелде, аларның белемнәре тигезләнде.

*Төп этап.*

Беренче дәрестә укучыларга Г Тукай турында алынган белемнәре искә төшерелә, мисаллар өстендә ныгытыла. Төркемнәр оештырылды. Проект - дәреснең эзлеклелеге турында презентация күрсәтелде, буклетлар таратылды. Дәрестә хәл ителергә тиешле проблема һәм уку мәсьәләләре билгеләнде. Мәгълүмат алу өчен чыганаклар аталды.Проектны тәкъдир итү алымнарын билгеләдек. Укучыларны проект эшенең формалары белән таныштырылды.

Икенче дәрестә проект төзү юллары төшендерелә, тема сайланыла, төркемнәр оештырыла. Башка темаларга укытучы тәкъдим иткән проектлар үрнәге карала. Болар барысы да укучы белән килешенеп эшләнелә: укучының шәхси теләге, кызыксынуы исәпкә алына. Проект эшләү этаплары һәм нәтиҗә формалары укучылар белән киңәшләшеп башкарыла. Эш барышында катнашучылар үзара мәгълүмат алыша, проектлау күмәк рәвештә төркемнәрдә алып барыла. Проектлау барышында төркемнәр һәм һәр укучы үз эшенә рефлексия ясый. Катлаулы мәсьәләләр буенча фикер алышырга өйрәнә. Дискуссияләр оештырыла. Укучыларга проектлау процессының катгый алгоритмга буйсынуы төшендерелә. Укучылар эш барышында кирәкле мәгълүматны эзләргә өйрәнәләр. Шуның белән беррәттән бу мәгълүматны үзләштерәләр.

Эзләнү эше өчен темалар ачыкладык:

I төркем “Гомерендә - халкы язмышы» (Г. Тукайның шәҗәрәсен өйрәнде)

Алар шагыйрьнең биографиясен өйрәнде, кайсы елда Г.Тукай кайсы шәһәрдә яшәгәнен күрсәтеп , “Тукай эзләре буйлап” карта – схемасын ясады, Г Тукайның кайсы елда , кем гаиләсендә яшәгәнен күрсәтеп таблица төзеде. ( 1 нче баганада авыл – шәһәрләр, 2 нче баганада – еллар, 3 нче баганада - эти –әниләренең исеме.)

II төркем без “Мин белгән Тукай” дигән темага презентация эшләде, иң охшаган бер шигырен ятлады.

III төркем “Тукай һәм музыка”(Г. Тукай истәлегенә язылган музыкаль әсәрләрне, Тукай әкиятләренең музыкада чагылышын өйрәнделәр) Алар Ф.Яруллинның “Шүрәле”, Ә.Бакировның “Алтын тарак”, Р. Гобәйдуллинның “Кисекбаш” балетларын, М.Шәмсетдинованың “Кәҗә белән Сарык” мюзиклын, Н.Җиһановның “Кырлай” симфониясен, М.Мозаффаровның “Тукай истәлеге” симфоник поэмасын өйрәнде, алар турында сыйныфташларына сөйләде. Бергәләп дисктан “Шүрәле” балетын карадылар. Шулай ук, “Тукай җырлый белгәнме? Операны ятратканмы? Аны башка халыклар беләме ?”- дигән сорауларга җавап эзләп, реферат яздылар. Г.Тукай сүзләренә язылган җырларны туплап, китапчык итеп чыгардылар, китапчыкка иллюстрацияләр ясадылар. Бу китачыкка барысы -28 җыр тупланган.. Китапчыкка кергән “И туган тел”җырын өйрәнделәр.

IV төркемне “Шүрәле биштәре” дип атадык. Бу төркем Тукай фотога төшәргә яратканмы - юкмы, нинди әдәби псевдонимнары булган, Тукай исемендәге дәүләт бүләген кемнәр алганлыгын ачыклады.. “Тукай – фотоларда” темасына презентация әзерләде, Тукайның әдәби псевдонимнары” темасына мәктәптә, урамда, өйдә сораштырулар үткәрде һәм аны видеоролик итеп эшләде. “Г Тукай премиясе лауреатлары” темасына альбом эшләде. Бу альбомга 1958 нче елдан бүгенге көнгә кадәр әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә бу премиягә лаек булган авторларны, кайсы әсәрләре өчен

бу премия бирелгәнен чагылдырды. Зурлар һәм кечкенәләр арасында "Г.Тукайның Һәркем белергә тиеш шигырьләре" дигән сораштыру үткәрде һәм 10 зурлар, 10 балалар белергә тиешле шигырьләрен ачыклап, плакат ясады.

*Йомгаклау этабы.* Проект темасы буенча ачык дәрес. Укучылар чыгышы.. Алдан бирелгән критерийлар белән укучылар иҗатын анализлау, бәяләү.

3 нче дәрес кабатлау дәресе итеп үткәрелә. Бу ачык дәрес рәвешендә уза, тыңлаучы һәм чыгыш ясаучыны киң аудиториягә ияләштерү максатыннан моны ачык дәрес итеп үткәрү бик тә зарур, чөнки тыңлаучы да, чыгыш ясаучы да үзләрен җаваплы итеп хис итәчәкләр. Җаваплылык хисе тәрбияләүдә менә дигән чара.

Бу проектны тормышка ашыру өчен күрсәтмә материаллар – буклетлар, төрле презентацияләр, китаплар , әкиятләр, табышмаклар җыентыгы интернет материаллары кулланылды, Г. Тукай сүзләренә язылган җырлардан китапчык эшләнде, шагыйрь һәм аның иҗаты белән бәйле музыкаль әсәрләр (Ф.Яруллинның "Шүрәле", Ә.Бакировның "Алтын тарак", Р. Гобәйдуллинның "Кисекбаш" балетлары, М.Шәмсетдинованың "Кәҗә белән Сарык" мюзиклы, Н.Җиһановның "Кырлай" симфониясе, М.Мозаффаровның "Тукай истәлеге" симфоник поэмасы) белән таныштырылды. Проект эшчәнлеге белән ата-аналар да таныш булды.

Г. Тукайның музыкага мөнәсәбәте нинди булган? Ул җырлый белгәнме? кебек проблемалы сорауларга җавап эзләдек, Г. Тукайның иҗаты, тормыш юлы, бүгенге көндә татар әдәбиятында тоткан урыны турында аңлатылды. Без бу проект өстендә эшләп балаларда шагыйрь иҗаты белән кызыксыну, аңа хөрмәт, күмәк эшләү, бер-берсе белән дус-тату эшләүне тәрбияләдек дип уйлыйм.

*Проектның перспективасын билгеләдек*: интернетта игълан ителгән иҗади конкурсларда катнашу, "Фәнгә беренче адымнар" дигән мәктәпкүләм фәнни – гамәли конференциядә катнашу, татар теле атналыгында куллану.

Минем уйлавымча, бу проект буенча башкарган эшләр, тыңланган һәм каралган музыкаль әсәрләр, матур рәсемле, ачык төсләр белән ясалган китапчыклар балалар күңелендә зур тәэсир калдырды, чөнки, аларның яңа сораулары, яңа фикерләре туа торды. Шуңа күрә мин үзебезнең алга куйган бурычыбыз үтәлде дип уйлыйм һәм проект методының балаларның иҗади сәләтен үстерүдә отышлы алым икәнен үз тәҗрибәмдә күрдем.

Кулланылган әдәбият:


1. Селевко Г.К. Современные образовательные технологии. М., 1998.
2. Хәмитов Р.Г., Салихова Л.Ф. Татар телен һәм әдәбиятын заман таләпләренә нигезләнеп укытабыз. ТР Бөгелмә муниципаль районы белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучыларының эш тәҗрибәсеннән: уку-укыту методик кулланма. – Казан: ТРМҮИ, 2015. – 160 б
3. Шәйхелисламов Р.Ф., Хөснуллина З.М., Зинина Н.Н., Земскова В.Н. Белем күтәрүче тыңлаучыларның проекты. Төп гомуми белем бирү оешмаларының татар теле һәм әдәбияты укытучылары. - Казан: ПМЦ ПК и ППРО КФУ, 2015. – 158 с.
4. Интернет ресурслары.

**Ширеева Алсу Сагитовна, учитель родного (татарского) языка и литературы МБОУ «Лицей № 4 г.Азнакаево»**

## ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ УКУЧЫЛАРНЫҢ ФУНКЦИОНАЛЬ ГРАМОТАЛЫЛЫГЫН ФОРМАЛАШТЫРУ АЛЫМНАРЫ

Аннотация

В данной статье даётся определение термину функциональная грамотность, функционально грамотный человек. Рассматриваются приемы формирования функциональной грамотности учащихся на уроках татарского языка и литературы.

*Ключевые слова: функциональная грамотность, функционально грамотный человек, инновационные педагогические технологии, мотивация.*

Функциональ грамоталылык нигә кирәк соң? Күпләргә бу компетенция белем бирү программасында PISA дөнья мониторингыннан соң барлыкка килгән кебек тоелырга мөмкин. Чынлыкта исә, бу бөтен дөньяда барган үзгәрешләр белән аңлатыла. Катлаулы һәм тиз үзгәрүчән чынбарлыкта яшәү өчен, бүгенге мәктәп укучыларына яңа белем һәм күнекмәләр кирәк. Бүген безгә көн саен һәм сәгать саен бертуктаусыз мәгълүмат ага. Элек аның чыганагы бары тик газета-журналлар һәм телевидение генә булса, бүген исә бөтендөнья глобаль челтәреннән файдаланмаган яшь кешене күз алдына китерү кыен. Интернет челтәрендә товарлар сатып алырга, эшләргә, белем алырга, вебинарлар һәм видеоконференцияләрдә катнашырга, хәтта дәүләт органнарына да мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Шуңа күрә дә һәр килгән мәгълүматны аңлау, анализлау һәм куллана белү мөһим күнекмәгә әверелә. Шулай итеп, басым мәгълүматны җыюдан һәм истә калдырудан аны дөрес куллана белү күнекмәсен үзләштерүгә күчә. Бу күнекмә бүген яшь кешегә үзен җәмгыятьтә ышанычлы тою өчен бик кирәк.

Укучылар үсешенең уңышлы траекториясен төзү өчен нинди һөнәри һәм гамәли күнекмәләр кирәк булачагын алдан фаразлый алмыйбыз, ләкин функциональ грамоталыкларын арттыру, һичшиксез, киләчәктә тормыш позицияләрен ныгыту өчен ярдәм итәчәк.

Функциональ грамоталылык нәрсә ул?

Функциональ грамоталылык ул – мәктәптә алган белем һәм күнекмәләрне тормышта куллана белү. Шулай ук функциональ грамоталылык төшенчәсенең башка, фәнни билгеләмәләре дә бар, мәсәлән, кешенең тышкы тирәлек белән мөнәсәбәтләргә керә алуы, аңа максималь тиз җайлашу һәм эшләү сәләте.

Үз эченә нинди компетенцияләрне ала?

1. Уку грамоталылыгы. Язма текстларны аңлау, алар турында уйлану һәм фикер йөртә белү сәләте, социаль тормышта актив катнашу өчен, белем һәм мөмкинлекләрне киңәйтү.

2. Табигый-фәнни грамоталылык. Табигый-фәнни идеяләр белән бәйле мәсьәләләр буенча актив гражданлык позициясен биләү, күренешләрне фәнни аңлату, табигый-фәнни тикшеренүләр үзенчәлекләрен аңлау, мәгълүматларны аңлата белү һәм фәнни дәлилләрне куллану.

3. Математик грамоталылык. Математиканы төрле контекстларда формалаштыру, математик төшенчәләрне куллана белү.

4. Финанс грамоталылыгы. Керемнәр һәм чыгымнар белән идарә итү, акчаны дөрес бүлә белү.

5. Креатив фикерләү. Яңаны кабул итү, гадәти булмаган оригиналь фикерли белү, стандарт булмаган файдалы гамәлләр башкара алу.

6. Глобаль компетенцияләр. Конкрет күнекмәләр түгел, ә башка мәдәни тирәлеккә караган кешеләр белән шәхсән яисә виртуаль үзара хезмәттәшлек иткәндә кулланыла торган белемнәр, күнекмәләр, карашлар.

Кем соң ул функциональ грамоталы шәхес? Ул:

- дөньяда ориентлаша белүче, җәмгыятьнең кыйммәтләренә, планнарына, перспективасына туры китереп гамәлләр кылучы (үз гамәлләрен башка кешеләрнең гамәлләре белән чагыштыра һәм яраклаштыра, килештерә, яраштыра белүче, кешелек алдында торган бурычларга туры китереп гамәлләр кылучы);
- сайлау ситуациясендә һәм карарлар кабул итүдә мөстәкыйльлеккә ия булучы;
- үз гамәлләре өчен җавап бирә белүче;
- үзе һәм якыннары өчен җаваплылык тоючы;
- үз белемен даими баетып торучы;
- стандарт булмаган ситуацияләрдән чыга белүче;
- теләсә нинди социумда җиңел адаптацияләнүче һәм аңа актив йогынты ясаучы;
- үз фикерен яклый белүче һәм башкаларның фикерен хөрмәт итүче, кабул итүче;
- кешеләр белән аралашу чаралары- телдән һәм язма сөйләмгә югары дәрәҗәдә ия булучы;
- заманча мәгълүмати технологияләр белән эшли белүче;
- компетенцияләр җыелмасына (билгеле бер гыйльми хәбәрдарлык, мәгълүматлылыкка ) ия булучы.

Нәкъ менә шушы сыйфатларны бүген балаларда 1 нче сыйныфтан башлап чыгарылыш сыйныфны тәмамлаганчы заманча педагог тәрбияләргә тиеш һәм аларны хәзерге заман укучысы портреты буларак та китерергә мөмкин.

Функциональ грамоталылык формалаштыру - катлаулы, күп яклы, озак процесс. Педагоглардан да күп көч сарыф итүне таләп итә, чөнки фән буенча тирән белемнәр бирү генә соралмый, ә балаларны төрле тормыш шартларында бу белемнәрне кулланырга өйрәтү таләп ителә. Кирәкле нәтиҗәләргә бары заманча белем бирү педагогик технологияләреннән оста кулланып кына ирешеп була.

Функциональ грамоталылык – метапредмет төшенчәсе, шуңа күрә ул төрле мәктәп фәннәрен өйрәнгәндә формалаша. Телне өйрәнгәндә исә, күбрәк сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләренә ия булу һәм алардан җиңел файдалана белү күздә тотыла.

Укучыларның функциональ грамоталыгын тәэмин итү өчен, туган тел һәм әдәбияты укытучысы нәрсә эшли ала соң? Барыннан да элек, һәр укучыны белем бирү киңлегендә алга җибәрү өчен уңай шартлар тудырырга кирәк, дип уйлыйм мин. Моның өчен һәр яшьтәге мәктәп укучыларының уку мөмкинлекләрен, яшь үзенчелекләрен белергә кирәк.

Мин уку елын укучыларның укыту эшчәнлегенә диагностикадан башлыйм, анда белем алу сәләте һәм интеллектуаль белемнәрнең формалашу дәрәҗәсе исәпкә алынган. Һәркайсының уку сәләтен билгеләп, билгеле бер эзлеклелектә класс белән эшләүнең

юнәлешләре дә билгеләнә: алгоритмнар төзү, сөйләм эшчәнлеге процессында телне гамәли куллану өлкәсендә күнегүләр системасын булдыру.

Бу планда инновацион педагогик технологияләрне куллану зур роль уйный. Тикшеренү методы, ми штурмы, критик фикерләү технологиясе, проект эшчәнлеге, продуктив уку технологияләре, Блум ромашкасы, текст белән эшләү алымнары, укытуның төркем һәм коллектив формалары. Әлеге технологияләр иҗади активлыкны үстерә, фикерләү эшчәнлеген формалаштыра, укучыларны үз карашларын якларга өйрәтә, материалны тирәнтен аңлауга ирешергә булыша.

Парларда, төркемнәрдә эшләү тәрбия бурычларын да хәл итәргә мөмкинлек бирә: сыйныфташлары белән хезмәттәшлек итү теләген һәм осталыгын арттыра.

Әлеге технологияләр кысаларында кулланыла торган алымнар укучылар иҗаты ихтыяҗын канәгатьләндерә, телдән һәм язма формада фикерләрне кыска итеп бәян итүгә сәләтләрен үстерә, фикерләү эшчәнлеген активлаштыра һәм, гомумән, төрле компетенцияләр формалаштыруга ярдәм итә.

Мәсәлән, «Беләм, белергә телим, белдем» алымын карап китик. Бу алым үзләштерелә торган материалны системалаштырырга һәм структуралаштырырга ярдәм итә торган интерактив алымнарның берсе. Таблицаны тутырганда укучылар таныш мәгълүмат белән яңалыкны үзара чагыштырырга өйрәнәләр.

Дәрес башында «Беләм» баганасына укучылар белгәннәрен таблицага язалар.«Белергә телим» баганасында актуальләштерелгән белемнәр нигезендә укучылар темага кагылышлы яңа сораулар формалаштыралар. Материал белән танышканнан соң дәрес ахырында рефлексия этабында бу таблицага киредән әйләнеп кайтыла һәм таблица тулысынча тутырыла. Укучы таблица аша дәрестә үзләштерелгән белемнәрнең күләмен чагыштырырга тиеш. Мәсәлән, мин дәрес башында исем сүз төркеменең кем? нәрсә? сорауларын белә идем, дәрес ахырында аның килеш белән төрләнүен белдем, кушымчаларын аерырга, сөйләмдә дөрес кулланырга өйрәндем.

Материалны өйрәнүгә мотивация тудыру чарасы буларак, «Дөрес - дөрес булмаган раслаулар» алымын карап үтәргә була. Укучыларга әле өйрәнелмәгән тема буенча берничә раслау тәкъдим итәм. Балалар үз тәҗрибәләренә таянып яки чамалап кына дөрес раслауларны сайлый. Нинди раслауларның дөрес булуын ачыклау өчен, рефлексиядә бу алымга кире әйләнеп кайтабыз.

«Фаразлар агачы» алымы укучыларның образлы фикерләүләрен, фантазияләрен үстерергә, факт белән фаразларны берләштерергә һәм перспектив уйларга өйрәтә. Агачның кәүсәсе – чишелеш сорый торган тема, проблема, реаль ситуация, ботаклары – тема яки проблемадан чыккан төрле фаразлар, яфраклары – фаразларны дәлилләүче аргументлар. Бу алымнан әдәбият дәресләрендә текст уку барышында файдаланырга була. Текст тулысынча укылып бетми. Агач ясалып куела. Ботакларына текстың ахыры буенча күзалдына килгән вариантлары языла. Яфраклары булып текстан алынган фактлар, аргументлар табып язылып куела. Хикәяне тулысынча укып чыкканнан соң, укучыларның фаразлары анализлана, нәтиҗә чыгарыла.

Текстның эчтәлеген аңлау, шәхси мөнәсәбәтне ачыклау өчен, «Тукталышлар белән уку», «Аңлатмалы уку» , «Текст белән диалог төзү» алымнарын кулланам.

«Тукталышлар белән уку» алымы теләсә нинди мәгълүматка игътибарлы карарга, вакыйгаларның үсешен фаразларга өйрәтә, иҗади күзаллауны үстерә, укуны дәвам иттерергә этәргеч булган интриганы саклый. Укучыларга сорау, гипотеза яисә фикер

туган мөһим урыннарда тукталышлар ясау кирәклеген искәртәм, аларны истә калдырырга киңәш итәм. Укыганнан соң анализ ясыйбыз: тексттагы нинди сигналлар укучыны фикерләргә этәрде. Текст белән мөстәкыйль эшләгәндә, мондый «тукталышлар» укучы өчен табигый эшкә әйләнә.

«Аңлатмалы уку алымы» – фикерләүгә өстенлек биреп уку ысулы. Ул күбрәк текстны кабаттан уку барышында кулланыла. Комментарий кыска булырга тиеш, ләкин балалар уку барышында кызыклы фикерләр әйтсә, бу идеяләрне игътибарсыз калдырырга ярамый, укучыларның әдәби әсәр эчтәлегенә эмоциональ мөнәсәбәтләрен хупларга кирәк.

Текст белән эш итүнең нәтиҗәле формасы булып «Текст белән диалог төзү» алымы, ягъни уку барышында әсәр авторы белән табигый «әңгәмә» кору.

Гадәттә, язучылар үзләренең әсәрләрен «сер» белән тудыралар һәм шулай рәвешле сораулар тууга этәрәләр. Нindидер билгесезлек белән очрашу игътибарлылыкны «кабыза», фикер йөртүгә этәрә, күзаллауны активлаштыра, кызыксыну тудыра.

Текстны укыганда, аның белән «сөйләшәбез»: сораулар куябыз, җавапларын табабыз, аларның дөреслеген авторныкы белән чагыштырабыз. Бу диалог еш кына әсәрнең исемен укыганда ук башлана һәм текстта ачылмый калган сорауларга мөстәкыйль рәвештә җаваплар эзләү-табу белән тәмамлана. Текст белән диалогтан соң укучыга авторның әсәргә салынган уй-фикерләрен анализларга көчү җиңелрәк булачак.

Заманча мәктәп укучыларының мавыгуын чагылдыра торган кечкенә мәкалә язарга тәкъдим итү дә креатив характердагы уңышлы алым булып тора. Бу бирем төркемләп яки парларда эшләнсә, өстәмә рәвештә коммуникатив күнекмәләрне, эмпатияне һәм хезмәттәшлек итә белүне үстерергә дә ярдәм итәчәк.

Шулай итеп, санап үтелгән метод һәм алымнарны системалы куллану предмет компетенциясен үстерүгә хезмәт итә, ә алар нигезендә укучының функциональ грамоталыгы да формалаша.


Кулланылган әдәбият

1. Сәгъдиева И. Уку текстлары белән эш итү стратегияләре // Мәгариф, 2016 - № 8- б 58

2.https://sch1621.mskobr.ru/files/%20такое%20функциональная%20грамотность.pdf



**Эсметьева А.В.,**

**учитель родного ( чувашского) языка и литературы**

**МБОУ «Большешемякинская СОШ»**


## «АЧАСЕНЕ ЧӐВАШ ЧӖЛХИНЕ ВӖРЕНТЕС ӖҪРИ ҪӖНӖЛӖХ МАЙӖСЕМ» («ИННОВАЦИОННЫЕ ПОДХОДЫ В ОБУЧЕНИИ ЧУВАШСКОМУ ЯЗЫКУ»)

Пурнăç пĕр утăм чакмасăр малаллах шăвать. Учительсем те пурнăç уттинчен кая юлмасăр вĕрентӳ ĕçĕнче çĕнĕ технологисемпе усă курса ĕçлеççĕ.Вĕренӳри çĕнĕлĕхсене пула хальхи вăхăтра Раççейре вĕрентӳ-воспитани ĕçĕ-хĕлĕ палăрмаллах улшăнчĕ. Тĕп вырăнта – вĕрентекенсемпе вĕренекенсем пĕр-пĕрне ăнланса, çĕнĕ вĕрентĕве ăша хывса вăй хуни. Педагогикăри инноваци − чи çĕнни, çĕнĕлĕх, улшăну, вĕрентӳ ĕçĕнче çĕнĕ компонентсем кĕртесси, вĕрентекенпе вĕренекен пĕр тĕллевпе, меслетсемпе, майсемпе, пĕр капашпа, тĕрлĕ воспитани çул-йĕрĕпе, пĕрле ĕçлесе-шухăшласа, методика сĕнĕвĕсене тивĕçтерсе вăй хурасси.

Вĕрентӳри инноваци майĕсем, пĕр-пĕринпе тачă çыхăнса, вĕрентекенсене те, вĕренекенсене те, вĕсен ашшĕ-амăшĕсене те вĕренӳре, наукăра хăйне евĕрлĕ шухăшлама майсем туса пара ççĕ. Тăван чĕлхене юратма, пуплеве тĕрĕс йĕркелеме, илемлĕ калаçма, хутшăнма хăнăхтарса пырасси – чăваш чĕлхине вĕрентес ĕçри чи кирлĕ тĕллевсенчен пĕри пулса тăрать.Ачасен чăваш чĕлхине вĕренес туртăмĕ пысăклантăр, вĕсен ăс-тăнĕнче тăван чĕлхене лайăхрах, тĕплĕрех, тарăнрах пĕлес туйăм çуратас тесен, вĕренекенсене кăсăклантарма, илĕртме те пĕлес пулать.

Хальхи вĕренӳ стандарчĕсен тĕллевĕ те – çыннăн пĕлӳпе пултарулăх пахалăхне пăхса ăна малалла аталантарасси пулса тăрать.

Апла пулсан, ачасене паянхи пурнăç ыйтнă пек вĕрентес тесен тарăн пĕлӳ панисĕр пуçне шухăшлама, харпăр хăй тĕллĕн пĕлӳ пухма, пĕтĕмлетӳсем тума, йывăрлăхсене çĕнтерме те хавхалантармалла, уроксенче тĕрлĕ мелсемпе меслетсемпе, çĕнĕлĕхсемпе анлă усă курмалла.

Халĕ кашни шкултах компьютер, мультимедийлă проекторсем пур – вĕсем уроксене ирттерме çăмăлллăхсем кӳреççĕ. Çĕнĕ методика кăтартăвĕсемпе тĕрĕс усă курса хатĕрленĕ класс тулашĕнчи ĕçсен те, уроксен те тухăçлăхĕ пысăкрах. Пĕтĕçтернĕ (интегрированный) уроксем, класс тулашĕнчи ĕçсем ирттерни вара ачасене тĕрлĕ предметсен хушшинчи çыхăнăва туйма, чухлама, тĕпчеме май парать. Вырăс тата чăваш чĕлхипе çыхăннă материалсене пĕрлештерсе ирттерсен ачасем икĕ чĕлхе хушшинчи пĕр пеклĕхсене, уйрăмлăхсене сăнама, туйма вĕренеççĕ. Пĕтĕмлетӳсем туса чĕлхесемпе кăсăкланма пуçлаççĕ, наука тата тĕпчев ĕçне явăçаççĕ, пĕлĕвĕпе тавракурăмне анлăлатса пурнăçра хăйсен вырăнне тĕрĕс тупса палăртма хăнăхаççĕ. Ахальтен мар ĕнтĕ И. Я. Яковлев каланă: «Икĕ чĕлхе – икĕ ăс, виçĕ чĕлхе - виçĕ ăс», - тесе.

Курăмлăх хатĕрĕсем, ИКТ, ЦОР усă курни икĕ чĕлхене танлаштарса вĕренме май парать, техника хатĕрĕсĕмпе пĕлсе усă курни – ачасене тăван чĕлхепе литературăна юратса вĕренме хавхалантарать, материала тарăнрах ăса хывма майсем туса парать

Юлашки вăхăтра вĕрентӳ процесĕнче компьютер технологийĕсемпе анлă усă курма пуçларăмăр. Çак технологин вĕренӳ ĕçĕнчи мехелĕ самай пĕлтерĕшлĕ. Вĕренӳре компьютерпа тĕрлĕ ĕç тума май пур: кăтарту хатĕрĕ вырăнĕнче усă курма, пĕр-пĕр ăслая çирĕплетме, шырав-тĕпчев ĕçне йĕркелеме, кирлĕ информаци тупма, урока е унăн пĕр-пĕр тапхăрне вăйă евĕр ирттерме, хăнăхусемпе пĕлĕве тĕрĕслеме тата ытти те.

Тăван чĕлхе урокĕсенче Çĕрпӳ районĕнчи Михайловкăри вăтам шкулта чăваш чĕлхине вĕрентекен В.Ю.Андреев хатĕрленĕ «Чăваш чĕлхи» (5-7 классем валли) электрон вĕренӳ пособийĕсемпе усă курни тухăçлă. Вĕсемпе усă курса пĕлĕве тĕрĕслесе пыма та меллĕ. Çавăн пекех урокра çак автор хатĕрленĕ «Пĕлӳ шыраса» мультмедиллĕ вĕренӳ пособийĕпе те усă куратпăр. Вĕсемпе усă курни ачасене çĕнĕ темăна часрах ас туса юлма пулăшать. Электронла сăмахсар кирлĕ сăмахсене хăвăрт тупма пулăшать. Чăвашсен онлайн сăмахсарĕпе кашни урокрах усă курма меллĕ. Ку сайтра тĕрлĕрен чăваш сăмахсарĕсене

пухнă.

Уроксенче Power Point программăпа усă курни ĕç тухăçлăхне самай ӳстерет.Интернет та
урокра тухăçлă ĕçлеме май паракан форма. Унпа усă курма пĕлни кирлĕ информацие хăвăрт шыраса тупма май парать.

Интернет ресурспа усă курмалли майсем тем чухлех. Вăл вĕренекенсемпе вĕрентекенсене кĕске хушăра пысăк калăпăшлă информаци тупма çул уçса парать. Ачасене тĕнче тетелĕнче пĕр-пĕринпе çыхăну тытма, вĕрентекенрен инçет вĕренӳ мелĕпе тĕрлĕ ĕçсем илме, вĕсене пурнăçласа каялла ярса пама май па-рать. Чăваш чĕлхине вĕрентнĕ чух çĕнĕ технологи элеменчĕсемпе усă курни вĕренекенсене кăсăклантарма, пĕлӳ
шайне ӳстерме, çирĕп те тарăн пĕлӳ илме пулăшать.

Вĕренекенсем Инçет вĕренӳ мелĕпе тест, викторина ыйтăвĕсене хуравлама, тĕрлĕ инçет
конкурссенче, олимпиадăсенче хутшăнма пултараççĕ, ытти регионсенчи е ют-çĕршыври ачасемпе видеоконференцисем, чатсем йеркелеççĕ. Тĕрлĕ проект проблемисене пурнăçлама та Интернетран информаци илме пулать.

Паллах, чăваш чĕлхине вĕрентекенĕн пĕтĕм вĕренӳ материалне компьютерпа çеç усă курса вĕрентмелле марри çинчен те асра тытмалла. Традицилле уроксене те вĕрентӳ процесĕнчен кăларса пăрахмалла мар. Компьютер технологийĕсем логика шухăшлавне аталантарма, çĕнĕ информаци илме пулăшаççĕ, анчах та пĕр-пĕринпе чĕрĕ пуплев урлă хутшăнассин шайне чакараççĕ.

Проект меслечĕ ачан пултарулăхне аталантарма, пĕлĕвне ӳстерме, хăй тĕллĕн ĕçлеме, шухăшлама хăнăхтарать. Вĕренекенĕн пуçарулăхне ӳстерет, учительпе пĕрле шыравра ĕçлеме хистет. Ачасен пĕрлĕлĕх туйăмĕ ӳсет, этеплĕх, пĕр-пĕрне пулăшас кăмăл,
пăшăрханма пĕлесси, творчествăлла шухăшлав аталанать.

Проектсем тĕрлĕрен пулаççĕ. Вĕсем пĕччен, ушкăнпа ĕçлемеллисем, çырулăха аталантармаллисем, Интернет-проектсем тата ыт. те.

Проект вĕрентĕвĕнче вĕренӳпе воспитани тачă çыхăннă. Ку меслет ачасен коммуникативлă хăнăхăвĕсене çирĕплетет, шухăша кĕскен те витĕмлĕ калама, информацие
тĕрлĕ çăлкуçран пĕлсе пуçтарма, хальхи компьютер технологийĕпе чи кирлине шĕкĕлчеме
вĕрентет, чăваш тĕнчине кĕрсе çав чĕлхепе калаçас килнине ӳстерет. Юлашки вăхăтра çамрăксене патриотла воспитани парасси çине пысăк тимлĕх уйăраççĕ. Чĕлхепе тата патриотизмпа çыхăннă проектсем ачасене тăван çĕр-шыва, халăха, чĕлхене хисеплеме, юратма вĕрентеççĕ, хистеççĕ, вĕсенпе мăнаçланма хавхалантараççĕ

Паллах, паянхи интернет-ресурссемпе усă курса хатĕрленĕ çĕнĕ вĕрентӳ методикисем чăваш чĕлхине хăнăхнă йĕркепе вĕрентессинчен нумай уйрăлса тăраççĕ. Вĕренекенсене илемлĕ, тĕрĕс калаçма вĕрентес тесен, вĕсен умне чăн-чăн пурнăç ситуацийĕсене лартмалла. Проект ĕçĕ шăпах актуаллă технолги шутне кĕрет, вăл предметпа пуçтарăннă тарăн пĕлĕве пурнăçра кирлĕ пек усă курма пулăшать. Ачасем хăйсен тавра курăмне аталантараççĕ, вĕсен чĕлхи пуянланать, ытти çынсем калаçнине итлеме тытăнаççĕ, проекта хӳтĕленĕ чух пĕр-пĕрне ăнланма пуçлаççĕ. Вĕренекенсем справочниксемпе, словарьсемпе, тĕрлĕ литературăпа, компьютерпа ĕçлесе чăн, оригиналлă, тĕрĕс чĕлхе патне çитеççĕ. Çакна урокра учебникпа çеç вĕрентни çителĕклĕ мар.

Проект вăл – творчество ĕçĕ. Ача вĕрентекенпе е хăй тĕллĕн ĕçлесе тĕрлĕ проблемăна хускатать, çавна май унăн чĕлхене лайăх пĕлнисĕр пуçне, тарăн пĕлӳллĕ, коммуникативлă, интелектуаллă, пултаруллă пулмалла. Программа материалĕпе килĕшӳллĕн проектсен меслечĕ пур темăпа та каять. Вĕренекенсен фантазийĕ, ăслайĕ,

творчествăлла шухăшлавĕ, хăй тĕллĕн ĕçлесси тата вĕсен ырă енĕсем аталанаççĕ.
Хальхи технологисен шутне пĕрле ĕçлесе-вĕренмелли технологи (технология сотрудничества) те кĕрет. Унăн тĕп тĕллевĕсенчен пĕри вĕрентекенпе ачасен тĕрлĕ лару-тăрура пĕрле пуçаруллă та хăтлă условисенче ĕçлесси. Вĕренекенсем 3-4 çынран тăракан ушкăнсене пĕрлешеççĕ. Вĕсен умĕнче вĕрентекен пĕр çивĕч ыйту лартать, кашни ачан хăйĕн ятарлă ĕç пур, ача хăй ĕçĕшĕн çеç мар, ушкăншăн та яваплă. Вĕренӳре вăйсăртараххисем хăйсем ăнланманнине лайăх вĕренекенсенчен ыйтса пĕлме пултараççĕ, вăйлăраххисем яланах вĕсене пулăшма хатĕр. Çакăн пек ушкăн пысăк çитĕнӳсем тавать. Ачасем хăйсен çитĕнĕвĕпе хавхаланса тата та нумай пĕлме тăрăшаççĕ.
Ачасене вĕрентес ĕçре информаци технологийĕсене кĕртни сисĕм-туйăм процесне, шырав-тĕпчеве тĕрлĕ майлă, интереслĕ те кăсăклă тума пулăшать. Интернет та мультимеди
те кĕске хушăрах тĕлĕнмелле нумай информаци параççĕ, çавна пула ачасен вĕренес кăмăлĕ
ӳсет. Ачасем шыраса-тĕпчесе тупнă информацие хăйсемех ушкăнласа пахалама хăнăхаççĕ.
Мультимеди пулăшăвĕпе вĕренекенсем хаçат-журнасенчен, телевиденирен информаци пухаççĕ, хăйсем те интервьюсем илеççĕ.

Хальхи вăхăтра чăваш чĕлхине вĕрентес ĕçре çĕнĕ вĕрентӳ меслечĕсемпе те, традициллĕ, хăнăхнă йĕркепе вĕрентессипе те усă кураççĕ. Пурнăçра инноварциллĕ меслетсене аталантарнипе пĕрлех малтанхи традициллĕ меслетпе вĕрентессин пĕлтерĕшне
те çухатмалла мар. Вĕсем иккĕшĕ те пĕр шайра пулма тивĕç, яланах пĕр-пĕринпе тачă çыхăнса, вĕрентекенсемпе вĕренекенсене пулăшса пыччăр. Ахальтен каламан вĕт ваттисем кивви çĕннине упрать тесе.